ШИМБӘ
10 ФЕВРАЛЬ
1940 ел
№ 33 (5833)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—28, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

Партиянең җитәкче органнарын сайлаулар

ВКП(б) Үзәк Комитеты карары нигезендә шушы көннәрдә безнең барлык партия оешмаларыбыз отчет-сайлау кампаниясенә керешәчәкләр. Сайлаулар, башлангыч оешмалардан алып, өлкә, край һәм республика оешмаларынача, партиянең барлык оешмаларында, 1940 нчы елның 15 нче февраленнән 15 нче мартына кадәр булган вакыт эчендә үткәреләчәкләр.

Шушы карарны үтәү йөзеннән ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты бюросы партиянең авыл һәм шәһәр башлангыч оешмаларында партиянең җитәкче органнарын сайлауларны үткәрүне 15 нче февральдән 23 нче февральгә, ВКП(б) ның авыл райкомнарына һәм Зеленодольск шәһәр оешмасына сайлауларны 25 нче февральдән 3 нче мартка, шәһәр райкомнарына сайлаулар үткәрүне 25 нче февральдән 1 нче мартка, Казан шәһәр комитетына сайлаулар үткәрүне 3 нче марттан 7 нче мартка кадәр һәм партиянең XXI нче Татарстан Өлкә Конференциясен 10 нчы марттан үткәрүне билгеләде.

Партия органнарына соңгы сайлаулардан бирле ел ярымнан артык вакыт үтте. Бу вакыт эчендә безнең ил тормышында, партия тормышында гаять зур һәм бай вакыйгалар булды. Бу чор эчендә Совет иле Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә социалистик демократизмның яңа баскычына күтәрелде. Дөньяда иң демократик Сталинчыл конституция нигезендә СССР Верховный Советын сайлаган кебек үк, РСФСР, автономияле республикаларның Верховный Советлары һәм җирле советлар сайланды. Тарихи җиңүгә — коммунистлар һәм партиясезләр блогының яңа җиңүенә ирешелде. Совет халкының мораль һәм политик бердәмлегенең символы булган бу блок, безнең илдә гаять бөек көч булып әверелде, ул, большевистик партиянең массалар белән тыгыз һәм нык элемтәдә булуын бик ачык күрсәтә. Социалистик стройны ныгыту өчен көрәштә партиянең—хезмәт ияләренең алдынгы отрядының авторитеты чиксез үсте.

Бу чор эчендә партия тирәсендә яңа актив үсте һәм тупланды, сайлаулар кампаниясе вактында, безнең ил йөз меңнәрчә партияле һәм партиясез агитаторларны, гүзәл пропагандистларны, талантлы оештыручыларны тәрбияләп үстерде һәм аларны дәүләтнең җитәкче работниклары дәрәҗәсенә күтәрде. Яш талантлы работникларны күтәрү совет, хуҗалык оешмаларыбызны ныгытуга зур ярдәм итте һәм халык иҗадының, инициативасының үсешенә тагын да киңрәк юл ачты.

ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм бөек юлбашчыбыз иптәш Сталин җитәкчелегендә партиябез үзенең сафларын троцкичы - бухаринчы һәм буржуаз милләтче контрреволюцион элементлардан тазартуда гаять зур эш башкарды, кабәхәт бандалар тар-мар ителделәр. Партия аппаратына Ленин—Сталин эше өчен, коммунизм эше өчен чын күңелдән бирелгән, көрәштә чыныккан һәм сыналган иптәшләр күтәрелделәр. Партия алда торган сайлауларга монолит хәлендә, бердәм булып, Сталинчыл Үзәк Комитет тирәсенә нык тупланган хәлдә килә.

Алда торган сайлауларда иң мөһим бурыч— **„тулысынча тикшерелгән, партия эшенә чын күңелдән бирелгән һәм коммунистик партиянең эшен азагынача якларга сәләтле булган большевикларның партиянең җитәкче органнарына сайлануын тәэмин итү“.**

Партия органнарына социализм өчен көрәштә үзен эштә күрсәткән, намуслы, куркусыз, Сталинчыл Үзәк Комитетка ахрынача бирелгән большевиклар сайланырга тиешләр. Партия органнарын сайлаганда партиянең һәрбер оешмасы, һәрбер коммунист Ленинчел—Сталинчыл принциптан чыгып эш итәргә тиеш. Бары тик шундый принципиаль якын килү генә иң лаеклы, социализм эшенә чын күңелдән бирелгән работникларның сайлануын тәэмин итәр.

Яңа сайлаулар, большевистик тәнкыйт һәм үз-үзеңне тәнкыйтьләүне җәелдерү, партиянең эчке демократиясен тормышка ашыру партия аппаратын хиянәтчеләрдән, партия органнарына очраклы үтеп керүчеләрдән, сүзләре эштән аерылган кешеләрдән ахрынача тазартырга ярдәм итәр.

Демократик централизмның большевистик принципы ул,— партиянең барлык җитәкче органнарының югарыдан алып түбәнгәчә сайланулары гына түгел, бәлки партия органнарының үз оешмалары алдында әледән-әле отчет биреп торуларын да мәҗбүри икәнлеген аңлата. Отчет биреп тору, сайлаулар кебек үк, большевистик тәнкыйтькә киң юл ача һәм тынычланып калуга, гамсезлеккә каршы көрәштә әһәмиятле корал булып тора.

„Партиянең җитәкче органнарына булачак сайлаулар ВКП(б) ның XVIII нче съездының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының май пленумы карарларын партоешмаларының үтәүләрен тикшерү билгесе астында, ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарларын һәм партия оешмалары алдында тора торган политик һәм хуҗалык бурычларын уңышлы үтәүгә массаны тагын да туплау билгесе астында үткәрелергә тиеш“.

Үзәк Комитетның бу күрсәтмәсе партиянең барлык оешмаларыннан политик - масса һәм агитация-пропаганда эшен тагын да җанландыруны таләп итә. Оборона эшен, массаларны интернационал рухта тәрбияләү эшен көчәйтергә, партиянең һәрбер оешмасының идея тормышын югары дәрәҗәгә күтәрергә кирәк. Партия оешмалары ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съезды карарларын һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының январь пленумы карарларын тулысынча тормышка ашырырга, партия членына индивидуаль, дифференциаль якын килүне партия эшенең нигезе итеп алырга тиешләр.

Язгы чәчүгә үрнәк рәвештә хәзерләнүне, яңа үсеп чыккан йөзпотчылар хәрәкәтен җәелдерүне һәм аңа җитәкчелекне көчәйтү, промышленностьның эшен киләчәктә дә яхшырту, халык хуҗалыгының барлык участкыларында дәүләт планнарын үтәү һәм арттырып үтәү—һәрбер партоешма җитәкчесенең төп бурычы әнә шул.

Массаларның политик активлыгын һәм революцион уяулыгын күтәрү, сайлау тәртибе белән һәрбер коммунистны яхшылап таныштыру, сайлауларны оешкан рәвештә үткәрүгә партияле массаларны туплау—һәрбер партоешма җитәкчесенең төп бурычларыннан берсе.

Партия органнарына социализм эшенә чын күңелдән бирелгән, партия эше, коммунизм эше өчен бөтен көчләрен, әгәр кирәк булса тормышларын да, бирергә хәзер торган большевекларны сайларга кирәк һәм шулай булыр.

ИПТӘШ СТАЛИННЫҢ БЕРЕНЧЕ ӘСӘРЛӘРЕ БАСЫП ЧЫГАРЫЛДЫ

Иптәш Сталинның тууына 60 ел тулуга карата ВКП(б) Үзәк Комитеты янындагы Маркс—Энгельс—Ленин институты И. В. Сталинның ике мәкаләсен: „Социал - демократия милли мәсьәләне ничек аңлый?“ һәм „Пролетарийлар сыйнфы һәм пролетарийлар партиясе (партия уставының беренче пункты уңае белән)“ дигән мәкаләләрен беренче тапкыр буларак „Большевик“ һәм „Партийное строительство“ журналларында (1939 нчы ел, № 23—24) рус телендә басып чыгарды. Иптәш Сталин бу мәкаләләрне грузин телендә язган һәм алар РСДРП ның Кавказ союзының сугышчан органында—„Борьба пролетариата“ („Пролетариатис брдзола“) газетасының 1904 нче елның 1/14 нче сентябрендә һәм 1905 нче елның 1/14 нче январендә чыккан 7 һәм 8 нче номерларында басылганнар.

Хәзер аларны госполитиздат аерым брошюралар итеп басып чыгарды. Аларның һәрберсенең тиражы—миллион данә. Якын көннәрдә брошюралар сатыла башлаячаклар. (ТАСС).

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән һәм шул вакытта батырлык һәм геройлык күрсәткәне өчен ССР Союзы Верховный Советы президиумы өлкән лейтенант Д. Л. Маргулиска Ленин ордены һәм „Алтын Йолдыз“ медале белән берлектә Советлар Союзы Герое исме бирде. РӘСЕМДӘ: Советлар Союзы Герое иптәш Д. Л. Маргулис.
Н. Демещенко фотосы (ТАСС фотоклишесе).

КЫЗЫЛ БАЙРАКЛЫ БАЛТЫК ФЛОТЫНЫҢ НАЧАЛЬНИКЛАР СОСТАВЫН ҺӘМ КЫЗЫЛ ФЛОТЧЫЛАРЫН СССР ОРДЕННАРЫ ҺӘМ МЕДАЛЬЛӘРЕ БЕЛӘН БҮЛӘКЛӘҮ

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм кыюлык күрсәткән өчен СССР Верховный Советы Президиумының указы белән кызыл байраклы Балтык Флотының начальниклар составыннан һәм кызыл флотчыларыннан 138 кеше СССР орденнары һәм медальләре белән бүләкләнделәр.

Ленин ордены белән капитан И. Р. Новиков, майор Е. Н. Преображенский, майор И. Г. Романенко, капитан Н. А. Токарев бүләкләнде.

„Кызыл Байрак“ ордены белән 73 кеше, „Кызыл Йолдыз“ ордены белән 22, „Почет билгесе“ ордены белән 2, „Батырлык өчен“ медале белән 4, „Хәрби хезмәтләре өчен“ медале белән 29, „аеруча хезмәт күрсәткән өчен“ медале белән 4 кеше бүләкләнде.

Фин ак гвардеецларына каршы көрәш фронтында командованиенең сугыш заданиеләрен үрнәк булырлык итеп үтәгән өчен һәм шул вакытта батырлык һәм кыюлык күрсәткән өчен СССР Верховный Советы Президиумы указы белән Кызыл Байраклы Балтык флотының „С—1“ һәм „Щ—311“ су асты көймәләренең личный составы орденнар һәм медальләр белән бүләкләнде.

Ленин ордены белән кече командир С. А. Алексашин, өченче ранг хәрби инженер А. А. Свитин, лейтенант В. А. Силин, өлкән политрук Н. К. Темнов, кече командир И. А. Мищенко бүләкләнде.

„Кызыл байрак“ ордены белән 25 кеше, „Кызыл Йолдыз“ ордены белән 52, „Хәрби хезмәтләре өчен“ медале белән 7 кеше бүләкләнде. (ТАСС).

Норвегия хатын-кызлары Маннергейм бандаларына ярдәм күрсәтүгә каршы чыгалар

ОСЛО, 8 февраль. (ТАСС). Норвегиянең „Арбейдерен“ газетасының хәбәр итүенә караганда, кичә Одда шәһәрендә (Норвегия) йорт хозяйкалары берләшмәсенең җыелышы булган. Җыелышта кабул ителгән резолюциядә йорт хозяйкалары Маннергейм Финляндиясенә ярдәм итүне туктатуны таләп итәләр. Алар Норвегиянең реакцион матбугаты тарафыннан Советлар Союзына каршы алып барыла торган яла ягу кампаниясенә каршы көрәшергә чакыралар.

АК ФИНЛЯНДИЯДӘ АЧЛЫК ҺӘМ ХӘЕРЧЕЛЕК

СТОКГОЛЬМ, 8 февраль. (ТАСС). Ак Финнәр кулындагы территорияләрнең халкы чиктән тыш мохтаҗлыклар кичерә. Ак Финляндия шәһәрләрендә һәм авылларында ачлык һәм хәерчелек гади күренеш булып әверелде. Илнең күп кенә районнарында ачлык барлыкны хәтта ак финнәр матбугаты да икрар итәргә мәҗбүр була. 23 нче январьда „Уси Суоми“ газетасы икмәк запаслары беткәнлекне хәбәр итте. Ваза шәһәрендә чыга торган „Вазабладет“ газетасы халыкка икмәкне азрак кулланырга тәкдим итә. Ак фин солдатына бары тик борчак шулпасы һәм солы боткасы гына ашаталар. Фин солдатлары арасында ризасызлык фактлары күп сизелә.

„Данцигер форпостен“ газетасының хәбәр итүенә караганда, Маннергейм бандалары халыкның барлык кием запасларын көчләп алып бетергәннәр. Ягулык җитми.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

8 нче февральдә фронтта сугыш хәрәкәтләре күпчелек хәлләрдә разведчикларның эзләнүләре белән чикләнде. Соңгы көннәрдә Карелия бугазында алгы пехота частьләренең бәрелешләре нәтиҗәсендә безнең частьләребез, тимер-бетоннан торган 8 артиллерия корылышы белән ныгытылган Хотинен районын (Сумма районы) алдылар. Ладога күле һәм Сувэнтоярви арасындагы участкыда безнең частьләр тимер-бетоннан эшләнгән 5 артиллерия оборонасы корылышын алдылар. Дошман һәр ике хәлдә дә зур югалтуларга дучар булды.

Безнең авиациябез хәрби объектлар өстенә уңышлы очышлар ясады.

Чит илләрдә

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 7 февраль. Гавас агентлыгы көнбатыш фронттагы сугыш хәрәкәтләре турында түбәндәге белдерүне тапшыра: „Һава яхшыру аркасында фронтта активлык тагын бераз яңарды. Ләкин сугыш операцияләре патрульләр хәрәкәте белән генә чикләнә.

Авиация хәрәкәте әйтерлек зур түгел“.

ПАРИЖ, 8 февраль. Кичә кич Парижда иглан ителгән рәсми белдерүдә болай диелә: „бөтен фронтта көн тыныч үтте. Рейн янында кайбер урыннарда пехотаның атышуы булды“.

Бүгенге иртәнге белдерүдә: „Кичә кич һәм төн буена фронтның төрле пунктларында патрульләрнең активлыгы көчәйгәнлеге күренде“ диелә.

БЕРЛИН, 8 февраль. Германия армиясенең верховный командованиесе түбәндәгеләрне хәбәр итә: „фронтның Саар участкысында артеллириянең бераз җанлануы һәм разведка хәрәкәтләре күренә“.

Дошман һәм нейтраль илләр сугыш башланганнан алып январь башына кадәр 409 сәүдә пароходларын югалттылар. Аларның бөтенесенең авырлыгы 1.493.431 тонна. Шул ук вакытта Германиянең хәрби диңгез көчләре гомуми авырлыгы 607.881 тонна булган 354 карабны тикшерү өчен Германия портларына китерделәр.

ЛОНДОН, 7 февраль. Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Эстониянең 800 тонна авырлыгындагы йөк пароходы „Ану“ Англиянең көнчыгыш ярлары якынында минага бәрелеп баткан. Команда составыннан 7 кеше коткарылган, 19 кеше — хәбәрсез югалган.

ЛОНДОН, 7 февраль. Рейтер агентлыгы Англиянең 4.300 тонна авырлыгындагы товар һәм пассажирлар ташый торган „Мюнстер“ пароходының минага бәрелеп һәлак булуы турында хәбәр итә. Команда һәм суднода булган барлык пассажирлар (200 ләп кеше) коткарылганнар. „Мюнстер“ Ирландия диңгезендә йөзүче беренче классы пароход иде.

Англия властьлары „Дейли уоркер“ газетасы хәбәрчеләренә виза бирүдән баш тарталар

ЛОНДОН, 8 февраль. (ТАСС). Англия хөкүмәте „Дейли уоркер“ газетасының ике хәбәрчесенә виза бирүдән баш тартты. Бу газетаның хәбәрчесе Фрэнк Питкерн Финляндиягә, ә икенче хәбәрчесе—Монтегю—СССР га барырга тиешләр иде. „Дейли уоркер“ газетасы, Англия властьларының Англиядәге күп кенә газеталарга үзләренең хәбәрчеләрен Финляндиягә дә, шулай ук СССР га да җибәрергә рөхсәт биргәнлекләрен күрсәтә. Газета болай дип яза: „Эшчеләргә карата Маннергейм бандаларының ерткычлыклары турында Норвегиядәге һәм Швециядәге эшчеләр газеталарында дөрес хәбәрләр чыкканлыктан Лондонда Маннергеймны яклаучыларның Фрэнк Питкерн кебек шаһидне булдырырга теләмәүләре аңлаешлы. Англия властьларының СССР да Айвор Монтегю кебек күзәтүче булуны да теләмәүләре бик аңлаешлы, чөнки ул Кызыл Армия турында капиталистик матбугатның ялганын фаш иткән булыр иде“.

Англиянең берничә күренекле эшлеклесе, шул исәптән Бернард Шоу, Англия хөкүмәтенең бу карарыннан үзләренең ризасызлыкларын белдерделәр.

Совет—Эстония мөнәсәбәтләре турында „Берлинер Берзенцейтунг“ газетасы

БЕРЛИН, 8 февраль. (ТАСС). Тартуда төзелгән тынычлык договорының 20 еллыгына багышлап чит ил эшләре министре Пийп сөйләгән речьне иглан итеп, „Берлинер Берзенцейтунг“ газетасы, Тартуда төзелгән договор—Эстониянең бөтен тышкы политикасының нигезе икәнлекле күрсәтеп үтә.

Газета, Англия Эстония халкын Советлар Союзына каршы сугышка котыртырга маташте дип яза. Үзара ярдәмләшү турында Эстония белән Советлар Союзы арасында пакт төзелүдән көнбатыш державаларының риза булмаулары очраклы хәл түгел. Газета болай дип яза: „Москваның политикасы Көнчыгыш Европада Англиянең элекке тышкы политикасы системасын күмгән лавина булды“.

Полякларның террорчылык оешмасы членнарын кулга алу

БЕРЛИН, 8 февраль. (ТАСС). Германия информация бюросының хәбәр итүенә караганда, Вильнода фаш ителгән поляк террорчылары оешмасының эшен тикшерү нәтиҗәсендә тагын да кулга алулар булган. Польшаның элекке полковнигы Владислав Шнейдовский кулга алынган. Ул яшерен оешманың кассиры хезмәтләрен үтәгән. Чит ил валютасындагы күп кенә акчага конфискация ясалган.

СЕНАТОР МАРСЕЛЬ КАШЕН „ЭШЕ“

ПАРИЖ, 8 февраль. (ТАСС). Франциянең атаклы коммунисты, хезмәт ияләренең властьлар тарафыннан ябылган „Юманите“ газетасының редакторы Марсель Кашен—Франция сенаты составында бердән-бер коммунист.

Реакционерлар депутатлар палатасында коммунистлардан үч алганнан соң хәзер Кашенны сенаторлык хокукларыннан махрүм итү мәсьәләсе куелды. Шушы теләк белән Даладьеның таләп итүе буенча сенатта махсус комиссия төзелде һәм бу комиссия сенатор Кашенның „эшен“ төзергә тиеш. Хәзер бу комиссия шушы „эш“ буенча материаллар „җыю“ белән шөгыльләнә.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

Көньяк Кытайда

Гуандун провинциясенең Кантон секторында япон гаскәрләре кытай гаскәрләренең Кантонга таба хәрәкәт итүләрен туктату теләге белән, Кантоннан 30 километр төньяктарак булган Синцзи станциясеннән көньяктагы тимер юлны шартлатканнар.

Үзәк Кытайда

Шушы көннәрдә генә Кытай партизаннары, Жуйчан-Унин шоссесе районында японнарның җәза экспедиция отрядына каршы засада ясаганнар. Партизаннар бу отрядка көтелмәгәндә һөҗүм итеп, 100 гә якын кешене үтергәннәр, шул исәптән ике офицер үтерелгән, шулай ук 20 җиңел пулемет, винтовкалар һәм башка төрле сугыш әйберләре кулга төшерелгән.

Шанхай районында кытай партизаннары соңгы көннәрдә японнарның Дачандагы, Лодяндагы һәм Цзянвандагы аэродромнарына һәм радиостанцияләренә берничә тапкыр һөҗүм ясаганнар.

Төньяк Кытайда

Сентраль Ньюс агентлыгының хәбәр итүенә караганда, японнарның Баотоу районында хәрәкәт итүче гаскәрләре, Хуанхе елгасы боздан арчылганга кадәр Суйюань провинциясенең көнбатыш өлешен басып алу өчен хәзер бу районда һөҗүм итә башлаганнар. Агентлыкның хәбәр итүенчә бу һөҗүмнең икенче сәбәбе, Япония сугыш чукмарларының бу районда уңышлы рәвештә сугыш хәрәкәтләре җәелдерү белән парламент карарларына йогынты ясарга теләүләреннән гыйбарәт.

Хэбэй провинциясендә 17 нче январьда кытай партизаннары Баодиннан 120 километр көньяктагы Нэйцю станциясе районында японнарның поездын шартлатканнар. Паровоз һәм берничә вагон җимерелгән.

ПАРТИЯ ТОРМЫШЫ

Партиянең җитәкче органнарына сайлауларга хәзерлек башланды

БАУМАН РАЙОНЫНДА

ВКП(б) ның Бауман райкомы башлангыч партоешмаларда отчет-сайлау җыелышларын үткәрүгә һәм партиянең район конференциясенә хәзерлек эшләренә керепте. 8 нче февральдә райкомда башлангыч партоешма секретарьларының киңәшмәсе булды, сайлауларга хәзерлек һәм сайлауларны үткәрү турында райком секретаре иптәш Суганов инструктив доклад ясады. Шулай ук киңәшмәдә, „Партиянең җитәкче органнарын сайлауларны үткәрү турында" ВКП(б) Үзәк Комитетының инструкциясе өйрәнелде.

Райком аппаратында эшләүче работникларның киңәшмәсендә райком эше буенча отчет докладына хәзерлек, башлангыч оешмаларда сайлауларны үткәрү графикасы һәм сайлау йомгаклары турында информация формасы тикшерелде.

Отчет-сайлау җыелышларына хәзерлек эшләре алып бару һәм җыелышларны үткәрү мәсьәләсендә булышлык күрсәтү өчен партиянең район активыннан 55 кеше башлангыч партоешмаларга беркетелде.

СТАЛИН РАЙОНЫНДА

Сталин районында партиянең җитәкче органнарын сайлауларга хәзерлек алып барыла. Районда 15 нче Февральдән алып 23 нче февральгә кадәр 115 башлангыч партоешмада отчет-сайлаулар үтәчәк.

7 нче февральдә башлангыч партоешмаларның секретарьлары белән инструктив киңәшмә үткәрелде. Киңәшмәдә „Партиянең җитәкче органнарын сайлауларны үткәрү турында" ВКП(б) Үзәк Комитетының инструкциясе өйрәнелде һәм отчет-сайлау җыелышларына хәзерлек эшенең практик чаралары күрсәтелде. Башлангыч партоешмаларда отчет-сайлау җыелышларын үткәрү графикасы билгеләнде.

Райком партия активыннан 50 кешене башлангыч партоешмаларга ярдәмгә беркетте.

9 нчы февральдә, ВКП(б) райкомы бюросы партиянең район конференциясенә хәзерлек чаралары турындагы мәсьәләне тикшерде.

ЗЕЛЕНДОЛЬСК ШӘҺӘРЕНДӘ

7 нче февральдә ВКП(б) нын Зелендольск шәһәр комитетының IV нче пленумы булды. Пленумда партиянең башлангыч оешмалары секретарьлары да катнашты. Пленум башлангыч партоешмаларда һәм шәһәр комитетында отчет һәм сайлаулар үткәрү мәсьәләсен тикшерде.

Шәһәр буенча партия органнарын сайлаулар февральнең 15 ннән алып, 23 сенә кадәр үткәреләчәк. 27 нче февральдә партиянең шәһәр конференциясе ачылачак.

ЛЕНИН РАЙОНЫНДА

Партиянең җитәкче органнарын сайлауларны уздыруга хәзерлек эшен ВКП(б) нын Ленин райкомы иң элек үз аппаратының работникларын моңа хәзерләүдән башлады.

7 нче февральдә райком работникларының киңәшмәсе булды. Монда, ВКП(б) Үзәк Комитетының инструкциясе өйрәнелде һәм районндагы башлангыч партоешмаларда һәм завод партоешмасында уздырылачак отчет-сайлау җыелышларының графикасы каралды. Аннан соң, шул ук мәсьәлә буенча районндагы башлангыч партоешма секретарьларының киңәшмәсе уздырылды. Бу киңәшмәдә сайлаулар турындагы инструкцияне өйрәнү һәм җыелышлар уздыруның графикасын тикшерү белән бергә, партоешмаларның отчет-сайлауларга хәзерлек мәсьәләләре буенча инструктаж бирелде.

Предприятиеләрдәге һәм учреждениеләрдәге партоешмаларда, заводта һәм аның цех партоешмаларында отчет-сайлау җыелышлары 15 нче февральдән 22 нче февральгә кадәр барачак. Отчетлар төзү, җыелышларны хәзерләү һәм аларны уздыру эшенә булышлык күрсәтү өчен райкомның пленум членнары башлангыч партоешмаларга беркетелделәр.

МОЛОТОВ РАЙОНЫНДА

7—8 нче февральдә, ВКП(б) ның Молотов райкомы башлангыч партоешма секретарьлары һәм райком тарафыннан партоешмаларга беркетелгән вәкилләрнең киңәшмәсен үткәрде.

Киңәшмәдә, башлангыч партоешмаларда отчет-сайлау җыелышларын үткәрү турында тикшерелде һәм „Партиянең җитәкче органнарын сайлауларны үткәрү турында" ВКП(б) Үзәк Комитетының инструкциясе өйрәнелде.

Шулай ук, җитәкче парторганнар сайлауларны үткәрү планы тикшерелде. Район күләмендә башлангыч партоешмаларда сайлаулар 15 нче февральдән алып, 23 нче февральгә кадәр барачак.

БУА РАЙОНЫНДА

Буа райкомы башлангыч партоешмаларда булачак отчет-сайлау җыелышлары уңае белән райком пленумы членнарының һәм башлангыч партоешма секретарьларының киңәшмәсен үткәрде. Киңәшмәдә, „Партиянең җитәкче органнарын сайлауларны үткәрү турында" ВКП(б) Үзәк Комитетының инструкциясе өйрәнелде һәм отчет-сайлау җыелышларын үткәрү планы тикшерелде. Райком карары буенча башлангыч партоешмаларда отчет-сайлау җыелышлары 17 нче февральдән алып 22 нче февральгә кадәр үткәреләчәк. Партиянең район конференциясе 27 нче февральдә башланачак.

Кандидатлар турында онытмаска

Биләр районының алдынгы эшчеләре, колхозчылары һәм интеллигентлары партия сафларына керәләр. ВКП(б) райкомы, партиянең XVIII нче съездыннан соң үткән вакыт эчендә, ВКП(б) членлыгына кандидат итеп 126 кеше, ВКП(б) га член итеп 48 кеше кабул итте.

Партиягә яңа кабул ителгәннәр арасында: Б. Поляна МТС ның трактор бригадасы бригадиры Хәлиуллин, Биләр МТС ынын алдынгы комбайнчысы Кузнецов, „Хезмәттәге батырлык өчен" медале белән бүләкләнгән Емелькино, тулы булмаган урта мәктәп директоры Бочкарев иптәшләр һәм башкалар бар.

Ләкин шуны әйтергә кирәк: районда аерым башлангыч партоешмалар партиягә кабул итү эшенә тиешенчә игтибар биреп житкермиләр әле. Мисаль өчен Сталин исемендәге колхоз партоешмасын алырга була. Бу колхозда партия сафларын үстерү өчен резерв зур. Колхозда 100 гә якын комсомол члены исәпләнә. 30 укытучы бар, колхоз активистлары саны да зур.

Ләкин партоешма активистлар арасында политик-тәрбия эшләрен юлга кую һәм аларның иң алдынгыларын партия сафларына тарту эше белән тиешенчә шөгылләнми. Шунлыктан, бу оешма бик акрын үсә. Мәсәлән, партоешма 1939 нчы ел эчендә ВКП(б) членлыгына кандидат итеп бары 5 кеше, ВКП(б) га член итеп 2 кеше кабул итте.

Оешмада, стажлары үткән кандидатлар саны 14 кешегә җитә. Шулардан: Шәйхеттинев, Закирова, Мингалимов, Мусин, Вәлиев иптәшләр 1932 нче елдан бирле кандидат булып торалар. Бу иптәшләр үзләренә тапшырылган эшне үрнәк рәвештә үтәп киләләр. Мәсәлән, иптәш Шәйхеттинев 1932 нче елдан 1938 нче елга кадәр кырчылык бригадасы бригадиры булып эшләде һәм икенче ел инде, терлекчелек фермасының мөдире булып эшли. Ул җитәкчелек итә торган ферма районда алдынгы фермаларның берсе булып тора. Башка кандидатлар да яхшы эш үрнәкләре күрсәтәләр. Ләкин, партоешма стажлары тулып үткән бу иптәшләргә (секретаре иптәш Ситдиков) ВКП(б) га член булып керү өчен бер төрле дә булышлык күрсәтми.

Б. Поляна колхозы янындагы партоешмада эш тагын да начаррак тора. Партоешма 1939 нчы елны ВКП(б) сафларына бер кеше дә кабул итмәгән. „Семеновод", „Канаш" колхозлары, Киров исемендәге колхоз янындагы башлангыч партоешмалар да бик акырын үсәләр. Бу оешмаларда партия кандидатларын ВКП(б) га член итеп күчерү эше бөтенләй алып барылмый.

ВКП(б) райкомы партия сафларын үстерү, кандидатларны ВКП(б) га член итеп күчерү эшенә җавапсыз караш фактларына чик куярга тиеш. Башлангыч партоешмалар кандидатларга ВКП(б) га член булып күчү өчен көндәлек булышлык күрсәтергә, ВКП(б) сафларын алдынгылар хисабына үстерүгә җидди игтибар итәргә тиешләр.

Ф. Кыямов.

Әлмәт районында дингә каршы пропаганданың куелышы йомшак

Хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлауларга хәзерлек уңае белән, Әлмәт районында партиянең кайбер оешмалары дингә каршы пропаганда эшен шактый яхшырттылар. Бишмунча авылындагы башлангыч партоешма (секретаре иптәш Зарипов) инициативасы буенча узган елның соңгы өч аенда дингә каршы темаларда хезмәт ияләре арасында 26 доклад куелган һәм беседалар үткәрелгән. Кәшер авылында да бу эш яхшы гына алып барылды.

Ләкин болар беренче адымнар гына әле. Партиянең күп кенә башлангыч оешмалары бу өлкәдә гафу ителмәслек эшлексезлек күрсәтәләр. Мәсәлән, Сөләй, Бигәш, Тихоновка һәм Колшәрип авылларында узган елның соңгы яртысында хезмәт ияләре арасында дингә каршы темаларда бер генә доклад та һәм беседа да үткәрелмәгән. Партиянең кайбер оешмалары бу мәсьәләнең торышы белән бөтенләй кызыксынмыйлар. „Иркен Юл" һәм „Яңа Тормыш" колхозы янындагы башлангыч партоешмалар (секретарьлары Җаббарова һәм Нәҗмиев иптәшләр) 1939 нчы елда дингә каршы пропаганданың торышы турында бер мәсьәлә дә тикшермәгәннәр.

Сугышчан алласызлар союзы оешмалары да начар эшлиләр. Колхозчыларны сугышчан алласызлар оешмасына тарту буенча аңлату эшләре алып барылмый. Мәсәлән, Сөләй авылындагы оешмада 15 член хисаплана. Алар арасында колхозчылардан бер генә член да юк. Нәдер, Чупай һәм Бигәш авылларында да шундый ук хәл.

ВКП(б) райкомының IX нчы пленумы дингә каршы пропаганда эшендәге кимчелекләрне бетерү буенча әһәмиятле чаралар билгеләгән иде. Ләкин сугышчан алласызлар союзының район советы (председателе ип. Хаҗиәхметов) пленумның бу күрсәтмәләрен үтәми. Сугышчан алласызлар союзының башлангыч оешмалары җитәкчеләренең киңәшмәләре бер тапкыр да үткәрелгәне юк. Шулай ук аларга эшләү юллары да күрсәтелми.

Хезмәт ияләре арасында дингә каршы пропаганда эше алып баруда комсомол оешмаларының роле зур. Ләкин Әлмәт районында комсомолның башлангыч оешмалары да һәм район комитеты да дингә каршы пропаганда эшеннән бөтенләй читтә торалар. Елдан артык вакыт эчендә комсомолның район комитеты бюросы утырышларында дингә каршы пропаганда мәсьәләсенең бер тапкыр да тикшерелмәве моны бик ачык күрсәтә.

Г. Баһаутдинов.

БӨТЕН КӨЧ, БӨТЕН ИГТИБАР ЧӘЧҮГӘ ХӘЗЕРЛЕККӘ!

КУКМАРА, 9 февраль. (Телефон буенча). Авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсендә безнең районнан 5 делегат катнашты. Без киңәшмәдән кайткач та, авыл хуҗалыгы алдынгыларының район күләмендәге киңәшмәсен чакырдык. Киңәшмәдә 350 кеше катнашты. Киңәшмәдә Кукмара белән Балтач районы арасында төзелгән социалистик ярыш договорына кул куелды. Хәзер бөтен көчне, барлык игтибарны чәчүгә хезерлеккә түплыйбыз.

Безнең Кукмара районы быел бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 13 центнер иген уңышы алуга ирешүне йөкләмә итеп алды.

Киңәшмәдән соң районда ефремовчы 52 звено оештырылды. „Дружба", Мәмәшир, „Тырыш", „Стахановчы" колхозларында даими звенолар оештырыла башлады.

Социалистик ярышны тагын да киңрәк җәелдерү нәтиҗәсендә, Янил МТС ы бүген—9 нчы февральдә тракторларга ремонт эшен тәгәлләде.

Кукмара МТС ы тракторчысы, республика күләмендәге киңәшмә делегаты иптәш Курамшина киңәшмәдән кайткач, тракторларга ремонт ясау буенча башка тракторчыларга булыша башлады. Ул көнлек норманы 150—160 процент үти.

Киңәшмә делегаты иптәш Ишмөхәметов техника культуралары чәчеләчәк җиргә кертү өчен минераль ашламалар хәзерләү чарасына кереште. Әзлән колхозы звеноводы, киңәшмә делегаты иптәш Афанасьева җирле ашламалар хәзерләүне шактый көчәйтте. Ул үз звеносында басуга тирес чыгару буенча кышкы планны 70 процентка үтәде инде.

Язгы чәчүгә иң яхшы итеп хәзерләнгән колхозга тапшыру өчен районның күчмә кызыл байрагы хәзерләнде.

С. Ш. Шакиров.

Кукмара район җир бүлеге мөдире, авыл хуҗалыгы алдынгыларының республика күләмендәге киңәшмәсе делегаты.

ФЕРМАЛАРДА ЭШ ЯХШЫ БАРА

Биләр районы, Сталин исемендәге колхозның терлекчелек фермалары районда алдынгы фермалардан санала. Аларда 230 баш сыер һәм 223 баш сарык бар. Фермадагы барлык терлекләр җылы абзарлар һәм азык белән тәэмин ителгәннәр. Бозаулар һәм бәрәннәр өчен дә махсус җылы урыннар хәзерләнгән. Фермаларда азык парлагычлар бар. Тупас азыклар парландырып, норма буенча ашатыла.

Фермалар мөдире Исбах иптәш Шәйхетдинов хезмәтне дөрес оештыруга нык әһәмият бирә, фермада эшләүчеләргә зур ярдәм итә. Терлекләр группаларга бүленгән, аерым тәрбияләүчеләргә беркетелгәннәр. Һәр кем үзенең терлекләрен яхшы карау белән һәм аннан күп продукция алу белән кызыксына. Хезмәт көннәре терлекләрне тәрбияләүнең сыйфатына һәм алардан алынган продукциянең күләменә карап языла.

Терлек караучылар үзара ярышып эшлиләр. Ярыш договорларының үтәлеше айга ике тапкыр тикшерелеп, нәтиҗәсе производство киңәшмәсенә куела.

Фермада эшләүчеләр өчен зоотехника укулары оештырылган һәм укуга фермада эшләүчеләрнең барсы да тартылган.

Сарык караучылардан стахановчы Муса Фәссәхев һәм Мортаза Минсафин иптәшләр соңгы ике ел эчендә 90 баш сарыктан 282 бәрән үстерделәр. 1940 нчы елда 140 баш сарыктан 200 баш бәрән алып үстерергә йөкләмә алдылар. Бу иптәшләр 1939 нчы елда Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсенә катнаштылар.

Сыер сауучы Гамбәр Хәмитова, Закирә Сәхипова һәм Абруй Арсланова иптәшләр дә яхшы эш үрнәкләре күрсәтәләр. Алар 1939 нчы елда 500—575 әр хезмәт көне эшләп, колхоз правлениесе тарафыннан 3 тапкыр бүләкләнделәр.

Ф.

Терлекчелеккә җитәкчелекне көчәйтергә

Соңгы елларда терлекчелек буенча да безнең уңышларыбыз бар. Мисаль өчеп Тымытык районын алам. Мин бу районда 1935 нче елдан бирле нәселле терлек үрчетү буенча зоотехник булып эшлим. Хәзерге көндә районда яхшы нәселле 226 баш сыер, 89 баш дуңгыз һәм 105 баш сарык бар.

1938 һәм 1939 нчы елларда колхозларның терлекчелек фермаларындагы барлык терлекләрне дә без тик яхшы нәселле үрчеткечләр белән генә каплаттык.

Ясалма орлыкландыру эшенә безнең районда аеруча җидди игтибар бирелә. 1936 нчы елда районда ясалма орлыкландыру буенча бары 2 генә пункт бар иде. Хәзер аларның саны 8 гә җитте. Үткән елны сарыкларны ясалма орлыкландыру планын 110 процент, атларны ясалма орлыкландыру планын 111 процент итеп үтәдек.

Метислаштыру һәм башка төрле зоотехника чаралары үткәрү нәтиҗәсендә, соңгы елларда Тымытык районында терлекләр-



нең продукция бирүләре күп яхшырды. Үткән елны һәрбер прекос нәселле тәкәдән уртача 5 килограмм, метислардан 3 килограмм һәм район буенча барлык сарыклардан уртача 2,75 килограмм йон алдык.

Тельман исемендәге колхоз сарыклардан бәрән алу буенча бигрәк тә зур күрсәткечләр бирде. Үткән елны бу колхозда һәр 100 сарыктан уртача 172 бәрән алып үстерделәр. Чөнки биредә сарыкларны ясалма орлыкландыру эшен дөрес куюга бик нык игтибар бирделәр. Колхоз үткән елны тик сарык асрау фермасыннан гына да 23 мең сум доход алды. Дәүләткә 1.315 килограмм йон тапшырды.

„Яңа тормыш" колхозында да һәр 100 сарыктан 175 бәрән алуга ирештеләр.

Ләкин хәзерге көндә бездә әле метислаштырылган терлекләрне учетка алу эше яхшылап оештырылмаган. Моңа Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты тарафыннан да җитәрлек игтибар бирелми. Гомумән, терлекчелеккә карата Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариатының җитәкчелеген күп тапкыр яхшыртасы бар. 1935 нче елдан бирле Тымытык районына нәселле терлек үрчетү мәсьәләләре буенча Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариатыннан бер генә кеше дә килеп караганы юк.

Галләмова.

Тымытык район җир бүлегенең нәселле терлек үрчетү буенча зоотехнигы.

ФИН АК ГВАРДЕЕЦЛАРЫНА КАРШЫ СУГЫШЛАРНЫҢ ГЕРОЙЛАРЫ

СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ КОМБРИГ П. Е. ВЕЩЕВ

Комбриг Петр Эвгеньевич Вещев—гаят зур энергияле һәм тәҗрибәле күренекле хәрби начальник. Гражданнар сугышына катнашкан Вещев ак финнәргә каршы көрәшнең беренче көннәреннән үк үз подразделениеләренең хәрәкәтләренә җитәкчелек итеп, дошманның ныгытылган позицияләрен бер-бер артлы алып, дошманны геройларча кыйнады һәм куды.

Җиңүдән гыйбарәт булган фәндә ул бик яхшы оештыручы. Ул үзе үрнәк күрсәтте, һәр вакыт алда, һәр вакыт куркынычлы урыннарда булды, һәм аның подразделениеләре батырлык һәм дисциплиналылык үрнәкләре күрсәттеләр.

Вещев гаскәрләрнең барлык төрләренең хәрәкәтләрен нечкәлекләренә кадәр белде. Ул волокитаны, күп сөйләүне яратмады, турылыкны һәм дөреслекне яратты.

Урта буйлы, тулы гәүдәле, яхшы итеп кырынган, пөхтә итеп киенгән Вещев гади большевик командир үрнәкләрен күрсәтте.

Ул сугышчыны белде һәм аны сугыш осталыкларының бөтен нечкәлекләренә өйрәтте. Әгәр отделение командиры занятие вактында винтовка белән сугышта ничек эш итәргә кирәклекне яхшы күрсәтмәсә, ачык аңлатмаса, ул винтовканы үзе ала иде һәм окопта ятып һәм тезләнеп ничек атарга кирәклекне үзе күрсәтә иде.

Бер вакыт мондый вакыйга булды. Вещев бер подразделениегә килә, аны тәҗрибәсез дневальный каршы ала, комбригны күрү белән дневальный аптырап кала һәм нәрсә эшләргә белми.

— Сез, нәрсә, иптәш сугышчы, дневальныймы?—дип сорый анардан комбриг.

— Так точно, дневальный.

— Сез, нәрсә, дневальныйның бурычларын белмисезмени? Дневальный алай булырга тиеш түгел. Бирегез әле монда противогазыгыз белән штыгыгызны.

Вещев противогазны һәм штыкны кия, һәм:

— Менә хәзер мин дневальный, ә сез командир янына барып, аңа, комбриг Вещев сезнең казармага килүегезне сорый диегез,—ди.

Сугышчы китә, ә комбриг дневальный булып кала. Полк командиры килеп керә. Вещев команда бирә:

— Смирно! ди, һәм бөтен формасын китереп аның янына бара һәм аңа рапорт бирә.

— Вольно,—ди командир.

Вещев:

— Вольно,—дип кабатлый да дневальныйга әйтә:

— Күрдегезме? Менә рапортны шулай бирергә кирәк! Эшче-Крестьян Кызыл Армиясенең сугышчысы нинди булырга тиешлеге хәзер аңлашылдымы?—ди.

— Аңлашылды, иптәш комбриг,—ди сугышчы,—һәр вакыт шулай эшләрмен.

Комбриг Вещев һәр нәрсәдә тизлекне, ләкин аңлы тизлекне ярата. Ул, сугышчының тук, киенгән, шат күңелле, батыр, инициативалы булуы өчен барлык чараларны күрде. Аның батырларны ничек тәрбияләвен күреп, сугышчылар аның турында: „Иптәш Сталин ничек өйрәтсә, безнең командир шулай эшли" диләр иде.

Вещев сугышчылар белән бергә ашады, бер вакытны, сугышның беренче көннәрендә повар аңа кайнар аш ашату өчен термослары белән өч көн буена аның артыннан йөргән, чөнки ул сугыш эшләре турында кайгыртып, ашауэчүен оныткан.

Аның частьләре ак финнәргә каршы сугышка чыккач, алар хәрби осталык, батырлык һәм геройлык үрнәкләре күрсәттеләр.

Аның командирлары хәрби бурычны ничек кенә булса да үтәргә дигән какшамаслык ышаныч белән җиңүгә бардылар.

Сугышта нинди булса да тоткарлык барлыкны күреп, ул, команданы үз кулына алды, сугышчыларны һөҗүмгә алып барды һәм иң көчле ныгытмаларны алды.

Иң яхшы, батыр һәм алдынгы сугышчыларны ул үткен күзе белән бик тиз күрә иде. Мәсәлән, хәзер Советлар Союзы Герое булган кызыл армеец Ульяновның эшлеклелеген һәм сугышчан осталыгын ул беренче булып күрде.

Ул күн пальто, киез итек кигән, противогаз һәм пистолет таккан. Аны еракта бик тиз таныйлар һәм сөекле командир борчылмасын өчен һәр кем үсәргә тырыша иде.

Аның йокларга да, ашарга да вакты җитми иде, ул бу турыда аз кайгырта иде.

Беренче сугышлар бик яхшы үткәч һәм гаскәрләр чигенүче ак финнәр артыннан киткәч, ул: „Мине алда бер нәрсә дә борчымый, мине тыл борчый. Әгәр тыл фронтны сугыш кирәк-яраклары белән тәэмин итмәсә, фронтка юл юк. Әгәр подсумкалар буш булсалар—ул нинди сугыш булсын. Мин бер генә нәрсәне беләм: минем урным гаскәрләр белән сугышта булу, тылда да безгә хәзер ныклы кешеләрнең булуы кирәк".

Аның гүзәл ярдәмчеләре дә бик яхшы эшләделәр. Вещев юлларның начар урыннарын һәм сазламык участкыларда кайда, нинди урында кыен булачагын алдан ук әйтеп куйды.

Аның аруны белмәүче иптәшләре, командирлар һәм комиссарлар, бөтен юлны участкыларга бүлделәр, план эшләделәр һәм һәрберсе үз участкысы белән шөгылләнде.

Сугышчылар винтовка, балта, пычкы алып юл ясарга бардылар. Кешеләр искиткеч ныклык һәм тизлек белән эшләделәр. Алар 14 сәгатьтә 9 километр киттеләр. Юл салынды. Транспорт тиешле урнына килде.

Комбриг Токаревны урман эчендәге тар юлда очратты.

— Я, кухняләр белән эш ничек тора?—дип сорады ул.

— Кухняләр юлга чыктылар,—дип җавап бирде Токарев.

Төнлә ату кирәк-яраклары һәм ягулыклар—барсы да китереп җиткерелде.

Вещев алдынгы коммунист. Изелгән фин халкына ярдәмгә баручы социалистик дәүләт армиясе кешеләрен, бөек җиңүләр даны алган армия кешеләрен тәрбияләүче.

Аның сугышчыларыннан берсе, кыю разведчик, Ленин ордены белән бүләкләнгән иптәш Мупранов, комбриг турында: ул безне гражданнар сугышы тәҗрибәсендә өйрәтте һәм без бу тәҗрибәне икеләтә осталык белән кулландык, дип сөйләде.

Вещев приказ биргәндә, кыска итеп бирә: „Сез гаскәрләрнең алга баруларын тәэмин итәргә тиешсез".

Яки: „Миңа монда танклар булсын, миңа монда пушкалар булсын. Менә шул!".

Яки: „Техника фәлән урынга җибәрелергә һәм анда фәлән вакытта булырга тиеш".

Төннәрен бөтен штаб йоклаганда Вещевнең йокламыйча, үзенең планнарын соңгы тапкыр тикшергән вакытлары була иде. Иртә белән повар завтрак китерергә рөхсәт сорый, ләкин Вещев аңа: элек сугышчыларны ашатыгыз, мин һәр кайчан да өлгерермен, ди.

Бер сугышта штаб начальнигы аны сугышка җибәрмәгән. Ул аңа туп-туры караган да: „Сулдан әйләнеп чык, ә мин уңнан китәм" дип команда биргән һәм алга киткән.

Ул геройларны һәм батырларны тәрбияләде, хәзер инде аларның исемнәре бөтен совет халкына киң күләмдә билгеле,—ә алдагы, хәл иткеч сугышларда алар тагын да артырлар!

„Алга! Ватан өчен! Сталин өчен!" дигән аваз сугышчыларны яңадан күтәрер һәм җиңүләр таңында, башка данлыклы исемнәр белән берлектә, гүзәл һәм аруны белмәүче большевик геройның — данлыклы комбриг Вещевнең да исеме балкыр!

Ник. Тихонов.

(„На страже родины" газетасыннан).

В. И. ЛЕНИН ИСМЕНДӘГЕ ҮЗӘК КӨТЕПХАНӘГӘ 75 ЕЛ

В. И. Ленин исмендәге Көтепханә работниклары коллективына

ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты В. И. Ленин исмендәге Үзәк Көтепханә работниклары коллективын көтепханәнең 75 еллык юбилее белән тәбрик итә һәм котлый.

В. И. Ленин исмендәге Үзәк Көтепханә, Советлар Союзы көтепханәләренең иң картларыннан берсе буларак, ТАССР хезмәт ияләренә большевизмны үзләштерергә, социалистик культураны үзләштерергә ярдәм иткәне хәлдә, зур иҗади эш алып бара.

ВКП(б) Өлкә Комитеты ышаныч белдерә ки, В. И. Ленин исмендәге Үзәк Көтепханә работниклары коллективы социалистик культураның чәчәк атуы өчен, хезмәт ияләре массасын коммунистик тәрбияләү өчен киләчәктә дә нык торып көрәшер.

Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) Партиясенең Татарстан Өлкә Комитеты.

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы В. И. Ленин исмендәге Үзәк Көтепханә работниклары коллективын 75 еллык юбилей белән чын күңелдән котлый.

В. И. Ленин исмендәге Үзәк Көтепханәнең тарихы безнең Татарстан республикасы халыклары культурасының җиңүчән үсеше тарихыннан аерылгысыз.

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы, соңгы елларда республикабыздагы иң зур культура учреждениеләреннән берсе булып әверелгән бу көтепханәнең тагын да үсүен чын күңелдән тели.

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы, партиянең XVIII нче съезды тарафыннан һәм бөтен дөнья хезмәт ияләренең бөек даһие һәм дусты иптәш Сталин тарафыннан куелган тарихи бурычларны тормышка ашыру өчен көрәшкә көтепханә работниклары тагын да күбрәк көч һәм энергия бирерләр дип тулы ышаныч белдерә.

Татарстан АССР Халык Комиссарлары Советы.

Бөтенсоюз Коммунистлар (большевиклар) партиясенең Казан Шәһәр Комитеты В. И. Ленин исмендәге Үзәк Көтепханәнең данлыклы 75 еллыгы көнендә аның работниклары коллективын кайнар рәвештә котлый.

ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты халыклар юлбашчысы В. И. Ленин исмен йөртүче Үзәк Көтепханә киләчәктә дә һәрбер укучының үсеп барган таләпләрен канәгатьләндерү өчен, хезмәт ияләренең киң массасы арасында Маркс—Энгельс—Ленин—Сталинның һәр вакытта җиңүчән теориясен популярлаштеру өчен туктаусыз көрәшер дип, хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләү өчен, социалистик фән һәм культураның чәчәк атуы өчен, Ленин—Сталин эшенең чәчәк атуы өчен, коммунизмның җиңүе өчен армый-талмый эшләрләр дип ышана.

ВКП(б) Казан Шәһәр Комитеты.

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты В. И. Ленин исмендәге Үзәк Көтепханә работниклары коллективын, көтепханәнең 75 еллык юбилее уңае белән, кайнар рәвештә котлый һәм социалистик Ватанга хезмәт күрсәтүдә аңа яңа уңышлар теләп кала.

Татарстан республикасының Үзәк Көтепханәсе 75 ел эчендә зур гына юл үтте, Татарстанда социалистик культураны үстерү буенча ул гаять зур эшләр башкарды.

Соңгы елларда көтепханәнең эшчәнлеге тагын да арта төште—ул Татарстан районнарында көтепханә эшен ныгыту буенча актив рәвештә катнаша башлады.

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты, хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләүдә, аларны Маркс—Энгельс—Ленин—Сталинның көчле таглиматы белән коралландыруда Үзәк Көтепханә киләчәктә дә гүзәл эш үрнәкләре күрсәтер дип ышанып кала.

Татарстан Мәгариф Халык Комиссариаты.

В. И. Ленин исмендәге Үзәк Көтепханәнең 75 еллыгы көнендә, Казан Шәһәр Советы кайнар сәлам җибәрә һәм социалистик культураны җәелдерү өлкәсендә һәм Ленин—Сталин партиясенә чын күңелдән бирелгән укучылар арасында иң яхшы эш оештыруда тагын да яңа уңышлар тели.

Казан Шәһәр Советының Башкарма Комитеты.

Көтепханәчелек һәм такдим библиографиясе буенча фәнни тикшеренү институты В. И. Ленин исмендәге республика Үзәк Көтепханәсенең данлыклы коллективын көтепханәнең җитмешбиш еллык юбилее көнендә кайнар рәвештә котлый.

Дирекция һәм җәмагат оешмалары.

САШАНЫҢ ТЕЛӘКЛӘРЕ

Саша Степанов—Татполиграфта квалификацияле электромонтер булып эшли. Яш Саша моның белән генә чикләнеп калырга теләми, ул күбрәк белергә, күп нәрсәләргә төшенергә омтыла һәм шул күбрәкне эзләү юлында Казанның Ленин исмендәге Үзәк Көтепханәсенә килеп керә. Бу—1930 нчы еллар була. Әнә шуннан бирле (димәк, ун ел!) Саша Степанов, республикабызның Үзәк Көтепханәсендә актив укучыларның берсе булып хисаплана.

Саша, барыннан да элек, матур әдәбияттан, Гогольдән башлый. Ул Гогольнең күп кенә әсәрләрен берничә кат укып чыга. Пушкин, Толстой, Достоевский, Успенский һәм башка күп кенә классикларны укый. Ниһаять, хәзерге заман язучыларына—Шолоховка, Тыняновка килеп җитә. Ләкин бу — тукталу пункты түгел. Саша Степанов аңа күп кенә яңа белем, яңа төшенчәләр биргән өлкән йортка—Үзәк Көтепханәгә, аның тырыш работникларына, көтепханәнең 75 еллык юбилее уңае белән рәхмәт әйтә һәм шул ук юбилей уңае белән түбәндәге теләкләрне белдерә:

Беренче. Көтепханәнең китап фондын үстерергә, баетырга кирәк. Юк исә укучыларның саны көннән-көн артып тору сәбәпле, кайбер китапларны озак вакытлар буена туры китереп булмый, ди Саша.

Икенче. Укучы массаның фикерен һәм сорауларын тагын да ныграк төшенү һәм эшне шуннан чыгып яңарта бару өчен, көтепханә работниклары белән укучыларның очрашуларын ешрак ясарга кирәк, ди.

Өченче. Язучылар, тәнкыйтьчеләр белән очрашуны көтепханәнең практикасына кертергә кирәк, ди ул тагын.

Күрәсез, Сашаның теләкләре—эшлекле теләкләр. 75 еллык бәйрәм уңае белән, көтепханә работниклары моңа, гади Сашаның гади һәм эшлекле тавышына аеруча колак салырлар дип уйлыйбыз.

Х.

В. И. Ленин исмендәге Үзәк Көтепханә бинасының тышкы күренеше.
И. Галиев фотосы.

Шагыйрьнең „Эзләр“е

(Әхмәт Фәйзи шигырьләре, Таттосиздат басмасы, редакторы Ибраһим Газый)

Әдәбиятта бик күп тантаным та, бер генә эз калдыра алмый торган кешеләр булалар. Шагыйрь Әхмәт Фәйзи андыйлардан түгел, ул безнең әдәбиятка үз аяклары белән атлап керде һәм аның үзенә хас эзләре кала. Шагыйрьнең 1939 нчы елда басылып чыккан „Эзләр“ дигән җыентыгы моны тагын бер кат раслый.

Әхмәт Фәйзи, барыннан да элек һәм барыннан да бигрәк, лирик шагыйрь. „Эзләр“ җыентыгында урнашкан шигырьләрнең дә күпчелеге лирик шигырьләр. Хәтта аның эпик тыйнаклык белән башлаган шигырьләре дә „лирика балыннан“ котыла алмаганнар, бу шигырьләрдә кай урында лирика туктап кайдан эпос башланып киткәнлекне әйтү дә читен („Күмелгән эзләр“, „Дала һәм кеше“, „Флейталар“). Ничек кенә булмасын, бу шигырьләрнең күпчелеге үзләренчә җылы, укыр өчен кызыклы, укучыны кузгата һәм ияртеп алып китә ала торган шигырьләр. Аларда хезмәт, хезмәтнең көче, яшьлек, яшьлекнең саташуы, дәрте һәм моңы чагылган.

Мәсәлән, шагыйрь үзенең „Күмелгән эзләр“ дигән поэмасында ары кагылып, бире сугылып „бәхет эзләп“ йөрүче һәм аракыны да, тормышны да төбенә чаклы эчәргә яратучы бер кешене сурәтли. Шешә төбеннән алына торган бер сәгатьлек „рәхәтлекләр“, ышанычсыз һәм киләчәксез яшәүләр бу кешене туйдыралар, ул кеше үзе дә сизмәстән түбәнгә таба тәгәри, тик ул төпкә бәрелеп ватылмый кала, чөнки аны хезмәт шигрияте эләктереп ала.

„...Әй ясадым. Малай, кара әле, син
Кодрәтенә эшнең, көченә:
Үзенекен итте, әкрен-әкрен
Өстерәде, тартты эченә...“

Юлдан язган кешеләргә юл күрсәтүче бөек нәрсәне—хезмәтне сөеп җырлавы белән бер рәттән, шагыйрьне яратып җырлый торган икенче бер темасы да бар, ул—кеше. Кешенең көче, горурлыгы, сәләтлелеге. Бу гади кеше генә түгел, бу бөек идеаллар — коммунистик идеаллар белән сугарылган кеше, бу—хәрәкәттәге кеше. Ул үзен көрәштә, героик эштә күрсәтә, ул куркуны һәм чигенүне белмәве белән матур. Шагыйрьнең „Дала һәм кеше“ шигыре бу яктан карагында аеруча характерлы.

„...Ком даласы. Эссе. Борчый торган
бимазалы тынлык,
Ат һәм кешенең һәрбер адымыннан
ясак сорый комлык...“

Дала ялангач һәм сары тәне белән кешенең каршына килеп баса. Дала үзенең „бимазалы тынлыгы“ белән кеше өстеннән шаркылдап көлә. Ат һәм кеше—икесе дә үләрлек булып сусаганнар. Фляжкада аз гына су бар, суга карап ат та, кеше үзе дә җылый. Ниһаять, кеше үзен кулга ала, идея ныклыгы кешегә көч бирә, кеше фляжкада калган суны атына эчерә, ат тагын хәл алып аякларын тыпырдата башлый һәм кеше юлын тагын дәвам итә...

Бик күп кыенлыкларны җиңеп Москвага рапорт белән килгән Төрекмәнстан атлыларын искә төшерә торган бу шигырь искиткеч көчлелек һәм гадилек белән язылган.

„Ак аю“ һәм башка күп кенә шигырьләрендә дә шагыйрь коммунистик идея белән сугарылган кешенең көчен, барлык кыенлыкларны, киртәләрне җимереп, алга баруын матур һәм ышандыра торган итеп сурәтләп бирә.

„Перчатка җыры“, „Шәһәрдә яз“, „Янгырдан соң“ шигырьләре үзләренең җылы оптимистик моңнары белән укучыны әсир итәләр. „Перчатка җыры“ нда шагыйрь халык әдәбиятындагы мактаулы традицияләрне бөек идея—ватанны сөю идеясе белән уңышлы рәвештә куша белү үрнәген күрсәтә.

„...Перчаткалар бәйләп салам, дустым,
Тизрәк барып үзенә юлыксын!
Салкын мылтык тотып постта торган
Сөйгәнемнең кулын елытсын.
Салкын мылтык тотып постта торган
Сөйгәнемнең күңелен елытсын...“

Болар янына тагын шагыйрьнең фәлсәфи интонацияле „Яфрак һәм чикләвек“, „Әкият“ шигырьләрен дә безнең әдәбиятта моңа чаклы күрелмәгән яңа һәм уңышлы адымнар итеп күрсәтеп үтәргә кирәк.

Әхмәт Фәйзи шигырь техникасын һаман саен ныграк үзләштерә, яңарта, яхшырта бара. Аның халык җырларындагы гадилек һәм табигыйлек традицияләренә якынлаша баруын, шигырьгә җиңел һәм юмористик нотаарны уңышлы рәвештә кертә белүен мактап әйтмичә китеп булмый.

* * *

Шулай да Әхмәттә барсы да ал да-гөл дип әйтеп булмый. Вакыты-вакыты белән Әхмәт Фәйзидә эстетизм бизгәге башланып китә һәм ул үзенең кайбер шигырьләрен нечкәртә-нечкәртә торгач ахрында артык нечкәртеп җибәрә. Аның мондый шигырьләре артык назлы булалар һәм алар аз гына кагылып китсәң дә ватылырга, чәлпәрәмә килергә торалар. Мондый шигырьләр киң укучылар массасы өчен булудан бигрәк, үпкәләгән кияүләр кәефен табу өчен язылган шигырьләргә ошыйлар.

Әнә шундый артык нечкәртелгән шигырьләрдән итеп „Кыядагы кыз“ һәм „Шаян март“ шигырьләрен күрсәтергә була. Шагыйрь монда нечкәли торгач шул чаклы нечкәртеп җибәрә ки, хәтта телефон аша ишетелгән „багрем“ сүзеннән дә бөтенләй исереп кала. Дөрес, сүз март турында, гади март кына да түгел, шаян март турында бара, шуның янына тагын ул „яшьлекне дә бәйдән ычкындырып“ ташлый, тик, ничек кенә булмасын, монда фальш бер ни белән дә төренмәгән көйгә ачыктан-ачык ярылып ята. Тойгыларда фальш булгач, аларны әйтә торган формада да, охшату һәм сурәтләү чараларында да фальшның булуы үзеннән-үзе аңлашылып тора.

„Әллә кемнәр тынта көлә-көлә
Боз эрчиләр, ломның тавышы
Зың-зың килә, аннан ныграк суккан
Минем йөрәк белән ярышып...“

Имештер, лом йөрәк белән ярыша! Моннан да ярлы һәм примитив охшатуның булуы мөмкинме соң?!

Әхмәт Фәйзинең кайбер шигырьләрендә очрый торган икенче җитешсезлек—тигез бер сулышның булмавы. Кайнап тотып була торган акылы реализм кайбер шигырьләрнең ахырларына таба кинәт сүнеп китә, „тыныч сулыш“ өзелә, шагыйрьнең үзенә хас интонациясе йомшый, күперенке фразалар, бизәкле тирада башлана һәм әнә шул рәвешчә үлчәү хисен ычкындыру аркасында кайбер хәлләрдә аңлашылмаулар да китә. Мәсәлән, „Күмелгән эзләр“ дигән поэманың герое, поэмада күренүенчә, революциягә чаклы ук, инде ут һәм су аркылы үтеп, инде үлеп инде терелгән кеше. „Күрдем, илләр күрдем, йөрдем, биек тау башларын гиздем“ ди ул үзе турында. Бер вакытны шулай безнең җиргә көчле яз килә. „Җимереп, шаулап, күкрәп килә бу яз“. Бу—революция шулай күкрәп килә. Ярый, бусы шулай да булсын, тик утнысуны кичкән теге конкрет кешене, башта гаҗәп дәрәҗәдә реаль булып сурәтләнгән кешене язның гомуми җылылыгы астына кертеп, эретеп калдырырга ярамый, аны шул конкретлыгы белән ахрына чаклы алып барырга, конкрет кешенең революциядәге конкрет язмышын ахрына чаклы күрсәтергә кирәк иде, шагыйрьнең моңа сулышы җитмәгән. Ул гомуми сүзләр һәм гомуми патетика астында конкрет язмышны эретеп калдырган. Нәк шундый ук хәлне „Кер юучы турында җыр“ дигән шигырьдә дә күрергә була. Патетика, күтәренке пафос асыл нәрсәләр, тик алар реаль дөньяның реаль сулышына комачауламаска, киресенчә, аны көчәйтүгә хезмәт итәргә тиешләр.

Тулаем алганда матур, шигри тел, җиңел һәм йөрәккә ятышлы тел белән язылган шигырьләрдә „Чәчкә көмеш көрәгәннәр“ „Күз юырта“, „Күп җырлар сикерде“ „Яш чәчрәттем“, „Кояш белән үбешү“, „Хәсрәткә без кырын“, „Безнең йөрәк бүре кебек ерткыч, аяусыз“ һәм „Юл ялап йөгергән елгалар“ шикелле уңышсыз сүзләр һәм ямьсез охшатулар киткәләгән. Әхмәт Фәйзи киләчәктә боларны искә алыр һәм үзенең шигъри телен тагын да баету турында уйлар дип ышанасы килә.

Гомумән алганда, бу „Эзләр“ шагыйрь Әхмәт Фәйзи иптәшнең дә, шулай ук безнең татар совет поэзиясенең тагын да үсеп, күтәрелеп килүен күрсәтүче шатлыклы эзләр булып торалар.

Фатыйх Хөсни.

ДАНЛЫКЛЫ ҖИТМЕШБИШ ЕЛЛЫК

Р. З. МӨХЕТТИНОВА
Көтепханәнең директоры

Татарстан республикасының В. И. Ленин исмендәге Үзәк Көтепханәсе Советлар Союзындагы иң карт көтепханәләрдән берсе. Көтепханә 1865 нче елның 10 нчы январенда ачылган. Ләкин көтепханәне ачу турындагы мәсьәлә күп иртәрәк—1830 нчы елларда кузгатылган. 1830 нчы елны „Ирекле экономик җәмгыять“ нең президенты адмирал Мордвинов губерналарда җәмагат көтепханәләрен ачу өчен средстволар табу турында эчке эшләр министрлегенә мөраҗәгать итә. Ул моны, „җәмгыятнең рухын күтәрүдә, фән һәм промышленность буенча яхшы әсәрләр өчен киң юл ачуда ярдәм итәр“ дип аңлата. Ләкин көтепханә ачу турындагы мәсьәлә коры сүз булып калудан ерак китә алмый. Көтепханә ачу турында сүзләр күп тапкыр кабатлансалар да, алар 14 ел буена тормышка ашырылмыйча калалар.

1844 нче елны Казан университетының тел бүлеге кандидаты Н. И. Второв Петербургка күчкәндә, үзенең атасы Казанда танылган библиофил И. А. Второвның җыелган китапларын Казанда җәмагат көтепханәсен ачу өчен губерна правлениесенә тапшыра. И. А. Второв шәһәрнең аз сандагы белемле кешеләрнең берсе була, ул, аеруча, рус әдәбиятын ярата, ул заманнагы барлык дип әйтерлек периодик басма әсәрләрне яздырып ала һәм аларны саклый. И. А. Второв көтепханәсенең котологын, И. А. Второвның университет буенча дусты, фән работнигы А. И. Артемьев төзи. Второвнын 903 исемдә 1908 том китабы була. Бу китаплар көтепханәнең нигезе булып әвереләләр. Ләкин губерна правлениесе бу бүләкне алганнан соң авыр хәлгә очырый. Второв китаплары шәһәр буенча үзләренә урын таба алмыйча бер урыннан икенче урынга, бер учреждениедән икенчесенә күчерелеп йөртеләләр. Бу вакытларда күп кенә кыйммәтле китаплар һәм шулай ук каталог та югалалар. Һәм бу башлангыч тагын 20 ел буена авыр атмосфера эчендә капланып кала, көтепханә кәгаздә генә булып, аның яшәве турында күп кенә гражданнар бер нәрсә дә белмиләр.

Бары тик 1864 нче елны, Н. И. Второвның үзе бүләк иткән китаплары турында искә төшергәч кенә шәһәр үзенең көтепханәсе турында уйлана башлый һәм 1865 нче елның 10 нчы январенда көтепханә ачыла. Көтепханәгә үз китапларын арттыру һәм баету өчен һәр елны 500 сум акча җибәрелә һәм ул, хәзерге Казан Шәһәр Советы бинасында урнаштырыла. Аның бер бүлмәсе һәм бер уку залы була. Ул бу йортта 1919 нчы елга кадәр яши.

Көтепханә ачылып бер атна үтүгә анда 110 кеше була. Шулардан университет студентлары—62 кеше, семинариядә тәрбияләнүчеләр—21, гимназиядә тәрбияләнүчеләр—14, укытучылар—8, чиновниклар—7, купецлар—7, хәрби кешеләр—7, руханилар—1 һәм разночинецлар—13 кеше. Бөек Октябрь Социалистик Революциясенә кадәр дип әйтерлек, укучыларның составы шундый булып кала.

Казан шәһәре көтепханәсенең китап фонды бик акрын үсә. 1901—1905 нче елларда китап фонды бары тик 1.363 китапка үсә, 1905—10 нчы елларда да өстәлгән китапларның саны шуннан артмый.

Бөек Октябрь Революциясеннән соң көтепханәнең эше бөтенләй үзгәрә. Аның эше Ленин—Сталин партиясенең җитәкчелегендә яңа баштан корыла. Көтепханә хезмәт ияләре массасын коммунистик тәрбияләүдә зур урын тотучы культура учреждениесе булып әверелә.

1922 нче елның сентябрь аенда Казан шәһәрендәге көтепханәләрнең работниклары берләшмәсе оештырыла, биредә көтепханә работниклары үз белемнәрен, квалификацияләрен күтәрү өчен тулы мөмкинлек алалар. Казанда көтепханәләрнең берләшмәсен оештыру—ул, көтепханәләр тормышында иң кыйммәтле культура-политик чара була. Ул, көтепханә эшләренең оештыру-методик мәсьәләләрен, көтепханә работникларының квалификацияләрен күтәрү мәсьәләсен хәл итүдә Главполитпросветка практик ярдәм күрсәтү өчен оештырылган иде.

Юбилярнең китап фондында тарих, философия һәм сәнгать буенча бөтен дөнья культурасы хәзинәләренең төп оригиналлары саклана. Биредә К. Маркснең 1872 нче елда рус телендә басылган „Капитал“ ның беренче басмасы, Михаил Ломоносовның 1755 нче елда басылган „Российская грамматика“ сы, А. Ф. Гильфердинг тарафыннан 1871 нче елның җәендә язылган кыйммәтле фольклор материалы „Онежские былины“ һ. б. бар.

„Көтепханә эше турында“ СССР Үзәк Башкарма Комитетының 1934 нче ел, 27 нче март карары Татарстан республикасындагы көтепханәләрнең эшләрен тамырыннан үзгәртте. Шул исәптән безнең көтепханәнең эш профиле дә үзгәрде. Ул 1934 нче елны, филиал-абониментны кушканнан соң, „В. И. Ленин исмендәге Үзәк Өлкә Көтепханәсе“, ә соңгарак „Республика көтепханәсе“ булып әверелә. Ленин исмендәге көтепханә коллективы үз алдына орденлы республикага лаеклы булырлык итеп эшләү бурычын куйды. Һәм ул үзенең 75 еллыгы көнен көтепханә эшләрен оештыру өлкәсендә гаять зур уңышлар белән каршылый. Партия һәм хөкүмәт көтепханәнең эшен киң җәелдерү өчен барлык шартларны булдырдылар. Аның бинасы Казанда иң матур йортларның берсе.

Хезмәт ияләренең сорауларын тулысынча канәгатьләндерү һәм аларны китаплар белән яхшы тәэмин итү—көтепханәнең эше әнә шуңа нигезләнгән. Көтепханәнең хәзерге вакытта матур итеп җиһазландырылган уку залы, абонименты, белешмә - библиография бүлеге, үзлегеннән өйрәнү кабинеты, методик кабинеты һәм обработка бүлеге бар. Көтепханәгә көненә 1.000—1.200 кеше килә. 1939 нчы ел эчендә генә дә көтепханәнең уку залында 129.271 кеше булган.

Көтепханә абонементында укучылар саны елдан-ел арта бара. Әгәр дә 1938 нче елны 9.067 кеше булган булса, 1939 нчы елны бу сан 10.191 кешегә җитте, шулар арасында татарлар 3.044 кеше санала. Көтепханәнең актив укучылар саны да арта бара. Алар арасыннан Татарстан АССР ның халык артисткасы Асия Измайлованы күрсәтергә мөмкин. Иптәш Измайлова марксизм - ленинизм классиклары әсәрләрен, сәхнә сәнгате техникасы турындагы китапларны һәм философия мәсьәләләре буенча булган әдәбиятны күп укый. 2 нче тегү фабрикасының сыйфат инспекторы М. А. Сонина рус һәм чит ил әдәбияты классиклары әсәрләрен аеруча яратып укый. Мондый иптәшләрне бик күп күрсәтергә мөмкин.

1939 нчы елда абониментка 103.923 кеше килгән. Бер ел эчендә 182.820 китап бирелгән. Иҗтимагый политик әдәбиятны алып укучылар саны елдан-ел арта бара. 1939 нчы елда көтепханә тарафыннан укырга бирелгән китапларның 42.599 ы политик китап иде. Шулардан 15.633 китап Маркс—Энгельс—Ленин — Сталин әсәрләре. 1939 нчы елда „ВКП(б) тарихының кыскача курсы“на, Маркс—Энгельснең „Коммунистик манифест“ына, Ленинның „Нәрсә эшләргә?“, „Бер адым алга, ике адым артка“, Сталинның „Ленинизм мәсьәләләре“ нә сорау аеруча үсте.

Көтепханә үзенең эшен, билгеле, китап бирү белән генә чикләми. Ул, әдәби кичәләр, докладлар, беседалар, конференцияләр үткәрә. Бәйрәмнәргә карата тиешле күргәзмәләр оештыра. Татарстан районнарындагы көтепханәләргә методик күрсәтмәләр бирә.

Көтепханә лаеклы кадрлар белән ныгытылган. Алар арасында социалистик ярыш методы киң кулланыла. Көтепханә работникларыннан кайберләрен бүген, көтепханәнең 75 еллыгы көнендә аеруча күрсәтеп үтәсе килә.

Менә В. А. Шевалина. Ул көтепханә эшендә 1921 нче елдан бирле эшли. Иптәш Шевалина укучылар арасында гаять зур авторитет казанды. Җәмагат эшендә ул актив катнаша. Яш кадрларны тәрбияләү эшенә иптәш Шевалина зур әһәмият бирә. Шуның белән бергә ул үз квалификациясен һәм политик белемен күтәрү өстендә тырышып эшли.

Татарстандагы көтепханә работниклары З. Ш. Хабибуллинаны бик яхшы беләләр. Ул үзенең гомуми һәм политик белемен күтәрү өстендә тырышып эшләү нәтиҗәсендә, зур уңышларга ирешә. Көтепханә эшенә ул 1919 нчы елны татар хатын-кызлары арасыннан иң беренче булып килгән иде. Хәзер ул көтепханәнең методик кабинетында эшли. Боларга тагын О. Г. Старцева, М. С. Иванова һәм башка иптәшләрне өстәргә мөмкин.

Көтепханәнең үткән 75 еллык тарихи юлы әнә шулай. Аның киләчәге тагын да шатлыклырак һәм перспективалары зур. Без бөек Ленин—Сталин партиясенең җитәкчелегендә, хезмәт ияләрен коммунистик рухта тәрбияләү эшен тагын да киңрәк оештырырга барлык көчебезне бирербез. Без көтепханә эшен Сталинчыл өченче бишьеллык бурычлары югарылыгына күтәрербез. Без көтепханәләрне бөек Ватаныбызның белем алу учагына, социалистик культураның төп тармакларыннан берсе итеп әверелдерү өчен армый-талмый көрәшербез.

Язу машиналары заводында митинглар

6 нчы февральдә Казандагы язу машиналары заводының барлык цехларында да, мехчыларның Татарстан республикасының 20 еллыгын производствода яңа уңышлар белән каршыларга чакырган мөраҗәгатен тикшерүгә багышланган митинглар булып үтте.

Җыю цехы эшчеләренең һәм эшче хатын-кызларының митингысында машиналар көйләүче механик иптәш Налорков болай диде:

— Безнең завод коллективы орденлы Татарстан республикасының 20 еллыгын производствода яңа җиңүләр белән каршыларга тиеш. Безнең машиналарны көйләү участкысы ярты еллык планны 25 нче июньгә үтәргә йөкләмә ала.

Мин җыю цехының бөтен коллективын Татарстанның 20 еллыгы исемендәге ярышны тагын да киңрәк җәелдерергә чакырам.

Стахановчы иптәш Камалова иптәш Нолорковның тәкъдимен яклап чыкты. Ул, мастер иптәш Антонов участкысы исеменнән, ярты еллык планны 25 нче июньгә үтәргә йөкләмә алды.

Инструментчылар да ярты еллык планны 25 нче июньгә үтәргә һәм механика цехы эшчеләрен яхшы штамплар, яхшы инструментлар белән тәэмин итәргә йөкләмә алдылар.

(ТатТАСС).

ЯҢА НОРМАЛАРНЫ АРТТЫРЫП ҮТИЛӘР

Өченче номерлы фанер заводы коллективы Татарстанның XX еллыгын хезмәт җитештерүчәнлеген үстерү белән каршылау өчен көрәшә. Күп санда продукция эшләп чыгару һәм аның сыйфатын тагын да яхшырту өчен рационализация чаралары үткәрелә.

Завод коллективы февраль аеннан яңа нормалар буенча эшләүгә күчте һәм аны бик тиз үзләштерде. Каезлау цехы стахановчысы, шәһәр Советы депутаты Шәйхуллин, клей пресcларында эшләүче Юдина иптәшләр яңа норманы 1,5—2 тапкыр арттырып үтиләр. Заводта хезмәт җитештерүчәнлеге элеккегә караганда 10 процент күтәрелде.

И. Фәйзи.

Ферганә тәҗрибәсе юл төзелешенә!

АЛДЫНГЫЛАРГА ТИГЕЗЛӘНИК

Ютазы районында авыл советлары председательләренең район киңәшмәсе булып үтте. Бу киңәшмәдә юл төзелеше мәсьәләсе тикшерелде.

Столбище районының „13 лет Октября“ колхозы членнарының Чкаловск трактын төзекләндерү һәм бу эштә Ферганә тәҗрибәсен куллану турындагы чакырулары зур күтәренкелек белән каршы алынды. Киңәшмәдә катнашучылар юл төзелеше эшен яхшы итеп оештырырга, социалистик ярышны киң җәелдерергә сүз бирделәр. Алар төзелеш материаллары ташуның еллык планын 1 нче апрельгә үтәргә йөкләмә алдылар.

Районда юл төзелеше буенча шактый эшләр башкарылды инде. 1 нче февральгә 2 мең кубометр грави ташы хәзерләнде һәм ташылды. Еллык план 30 процент үтәлде. Февраль аенда һәр көнне 200 кубометр материал ташу өчен бөтен чаралар күрелә.

Районда юл төзелеше буенча алдынгы колхозлар бар. Маркс исемендәге колхоз 1939 нчы елны зур уңышларга иреште. Бу колхоз юл төзелешендә үрнәк күрсәткәне өчен ВКП(б) Өлкә Комитетының һәм Татарстан Халык Комиссарлары Советының күчмә кызыл байрагы һәм бер автомашина белән бүләкләнде. Колхоз 1940 нчы елны тагын да яхшырак эшләү һәм район күләмендә беренчелекне алу өчен көрәшә. Юл төзелеше буенча махсус бригада эшли. Ул 1 нче февральгә 150 кубометр грави ташыды. Бригада членнары „13 лет Октября“ колхозының чакыруына зур оешканлык белән кушылдылар һәм ярыш йөкләмәсен үтәү буенча үрнәк күрсәтәләр. Алар грави ташу планын 1 нче мартка тулы үтәргә сүз бирделәр. Бригада членнарыннан Сәлимҗанов, Усманов, Ибраһимов, Галиев, Хафизов һәм башка иптәшләр грави ташуның көнлек нормасын арттырып үтәү өчен үзара ярышып эшлиләр.

„Игенче“ колхозының юл төзелеше бригадасы членнарыннан Шакиров һәм Харисов иптәшләр грави ташу буенча көнлек норманы 130 процент, „Яна Юл“ колхозы членнарыннан Батталов, Ситдиков һәм Зарипов иптәшләр норманы 124 процент итеп үтиләр.

Ферганә тәҗрибәсен юл төзелешенә күчерү буенча районда мондый үрнәк күрсәтүче колхозлар һәм колхозчылар аз түгел.

Ләкин әле бу әһәмиятле эшне онытучы колхоз председательләре дә юк түгел. „Авангард“, „Көрәш Бүләк“, „Якты Күл“ колхозлары шушы көнгә кадәр бер генә кубометр да грави ташымаганнар.

Ферганә тәҗрибәсен юл төзелешенә кыюырак күчерергә һәм бу эштәге җитешсезлекләрне бетерергә кирәк.

Шамгуллин.

КАЗАН ТИМЕР ЮЛЧЫЛАРЫНЫҢ ЯЛ ИТҮЕ

Узган елны Казан тимер юлчыларыннан курортларда—санаторийларда һәм ял йортларында 4.200 кеше булды. 93 кеше Сочида дәваланды һәм ял итте. 230 кеше Төньяк Кавказда—Кисловодский, Пятигорский, Железноводский һәм Ессентукида, 200 дән артык кеше Кырымның көньяк ярында булды.

Тимер юлчылардан йөзләрчә кешеләр Москвага, Ленинградка, Алтайга, Днепрогэска, Хәрби-Грузин юлына, Москва—Волга каналына, Балтык—Ак диңгез каналына һәм башкаларга экскурсияләргә бардылар. Берничә кеше Эльбрус тавы башына күтәрелде.

1940 нчы елны Казан тимер юлы работникларын дәвалау һәм ял иттерү эшенә бер миллион 900 мең сум акча тотылачак. Туризм эшләренә 74 мең сум акча җибәрелде. Январь аенда 89 кеше Кавказ һәм Кырым курортларында булды. (ТатТАСС).

КАЗАН ТУРЫНДАГЫ КИТАПЛАР КҮРГӘЗМӘСЕ

Казан Дәүләт университетының 135 еллыгы уңае белән, Татарстанның фәнни көтепханәсендә Казан турында басылып чыккан китаплардан күргәзмә оештырылды. Күргәзмәгә М. Ребушкинның 1834 нче елны „Казан шәһәренең кыскача тарихы“ дигән китабы, Николай Баженовның 1841 нче елны басылган „Казан тарихы“, шулай ук француз телендә чыккан „Казан“ дигән китап, А. П. Аристовның 1904 нче елны Петербургта басылган „Казан студентларының җырлары“ дигән китабы һәм башка китаплар куелган.

Күргәзмәдә Казан Дәүләт университетында укыган кешеләрнең, аерым алганда, Панаев, Загоскин, Лобачевский һәм башкаларның Казан турындагы истәлекләре белән дә танышырга мөмкин.

Казандагы пионерлар һәм мәктәп балалары йортындагы кыллы музыка түгәрәге Татарстан АССР ның XX еллыгына яңа җырлар өйрәнә. РӘСЕМДӘ—алгы планда—1 нче номерлы мәктәпнең (Сталин районы) 6 нчы класс укучысы Володя Веряскин.

А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

КЫЗЫЛ АРМИЯНЕҢ ҺӘМ ХӘРБИ ДИҢГЕЗ ФЛОТЫНЫҢ 22 ЕЛЛЫГЫ АЛДЫННАН

Хәрби диңгез клубында

Хәрби диңгез клубы, Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез Флотының 22 еллыгына карата, допризывниклардан 300 кешене „Моряк“ значогына норма тапшыруга хәзерли.

Предприятиеләрдә һәм ВУЗларда СССР ның Хәрби Диңгез Флоты турында беседалар үткәреләчәк.

Казан мәктәпләренең „Яш моряк“ түгәрәкләрендә өйрәнүче укучыларыннан 20 кеше 18 нче февральдә Аракчино затонына чаңгы походы үткәрәчәкләр. Алар анда судноларның кышлаулары белән танышачаклар. Аннары алар Аракчинодагы урта мәктәптә булып, бу мәктәптә укучылар белән үзләренең тәҗрибәләрен уртаклашачаклар.

Фәнни работниклар хәрби эшне өйрәнәләр

Казан университетының фәнни работниклары хәрби эш белән бик нык кызыксыналар, оборона түгәрәкләренә йөриләр. Ассистент А. Л. Негорошков Ворошиловча атучылар хәзерли. Аның түгәрәгенә фәнни работниклардан 15 кеше йөри. Алар арасында физика-математика фәннәре докторы К. З. Галимов һәм профессор Миропольский иптәшләр дә бар.

Доцент иптәш Н. В. Шмелев пистолетчылар хәзерләү түгәрәгенә җитәкчелек итә. Доцент иптәш Дистанов 50 дән артык кешене ПВХО значкисты итеп хәзерләде.

СССР Фәннәр Академиясенең член-корреспонденты Н. Г. Чеботарев, профессор В. А. Чердынцев, доцентлардан Успенский һәм Марков, ассистент Майоров иптәшләр 2—3 әр оборона значогы алдылар. (ТатТАСС).

КЛУБ БӘЙРӘМГӘ ХӘЗЕРЛӘНӘ

Серго Орджоникидзе исемендәге завод клубында Кызыл Армиянең һәм Хәрби Диңгез флотының XXII еллыгына хәзерлек бара.

Клубта Кызыл Армия еллыгына багышланган күргәзмә оештырыла. Шулай ук лекцияләр үткәрелә. 23 нче февральдә клуб сәхнәсендә үзешчәнлек сәнгате түгәрәкләренең көче белән зур концерт биреләчәк. Концертта татар һәм рус драма түгәрәкләре, җыр, кыллы оркестр түгәрәкләре һәм башка түгәрәкләр катнашалар.

Татар драма түгәрәге Кызыл Армия турында җыр һәм декламацияләр хәзерли. Җыр түгәрәге Хасан күле сугышлары турында ике җыр: „Ерак Көнчыгыш җыры“, „Присяга турында җыр“ һәм башка номерлар өйрәнә. Шулай ук кыллы һәм тынлы оркестрлар да Кызыл Армия көнендә булачак концертка зур хәзерлек алып баралар.

Ф. Басыйров.



Вахитов разъездында.
И. Галиев фото-этюды.

Хатын-кызлар тракторны өйрәнәләр

Мөслим районында берничә колхозда хатын-кызлар өчен эштән аерылмыйча тракторны өйрәнү курслары оештырылды. „Динамо“ колхозында 15, „Кызыл Октябрь“ колхозында 12 һәм „Мәгариф“ колхозында 15 хатын-кыз тракторчылар курсында укыйлар.

Якын көннәрдә районда тагын 3 колхозда—Рәхмәтулла исемендәге, „Туры юл“ һәм „Красный путь“ колхозларында курслар эшли башлаячак. Курсларга МТС ларның механиклары һәм трактор отрядларының бригадирлары җитәкчелек итәләр. (ТатТАСС).

Тизләтелгән темп белән төзүгә багышланган күргәзмә

Татарстанның Крайны Өйрәнү Үзәк Музеендә февраль ахырларында кызыклы күргәзмә ачыла. Ул тизләтелгән темп белән төзүгә багышланып, Бөтенсоюз төзелеш күргәзмәсе белән берлектә, Татарстан Үзәк Музее тарафыннан оештырыла.

Күргәзмә музейнең лекториендә булачак. Шунда ук Казанның төзелеш эшчеләре—ташчылар, штукатурачылар һәм техниклар өчен семинар-курс һәм кино-лекцияләр үткәреләчәк.

Колхозчылар культура җыемнарын срогыннан элек түлиләр

Татарстанда культура җыемнарын түләп бетерү срогы 15 нче февральдән 15 нче мартка кадәр билгеләнде.

Күп кенә колхозчылар үзләренең культура җыемнарын срогыннан элек түлиләр. Мәсәлән, Бондюг районының Песәй авыл советы (председателе ТАССР Верховный Советы депутаты иптәш Шәһидуллин) культура җыемнарын 3 көн эчендә җыеп бетерде. Әгерҗе районының Яңа Бизәкин авыл советына караган колхозчылар үз өсләрендәге җыемнарны бер көн эчендә түләп бетерделәр.

Опера театры концерты

Шушы көннәрдә Татар Дәүләт Опера театры артистларының концерты булды. Концертта театрның хоры, оркестры, солистлары һәм балет артистлары катнаштылар.

Концерт көчле оркестр тарафыннан үтәлгән Робеспьер увертюрасы (Витоль музыкасы) белән башланды. Артист Рудаков „Князь Игорь“ операсыннан Игорь ариясен һәм „Фауст“ операсыннан Мефистофль куплетларын җырлап, зур уңыш казанды. Бу артистта тавыш көчле, диапазон киң, техника яхшы.

Аерым номерлардан, артист Альмеевка тукталырга кирәк. Бу яш артист тавышының моңлы, ягымлы булуы һәм тәэсирле итеп җырлавы белән яратылып тыңлана. Ул көлкеле әйберләрне аеруча зур осталык белән башкара. Җәүдәт Фәйзинең „Карак песи“ ен ул тирән тойгы белән үтәп, нык алкышланды.

Театрның хоры башкаруында композитор Ревуцкийның „Сталин турында җыр“ ы, Покрассның „Кызыл Армия җыры“ һәм „Ворошилов, синең белән“ е, шулай ук Җиһановның „Сталин турында җыр“ м гаять көчле булып яңгырадылар.

Артист Артемов тамашачылар тарафыннан бик җылы каршы алынды. Ул „Мазепа“ операсыннан Мазепа ариясен һәм „Иоланта“ операсыннан Роберт ариясен гаять уңышлы башкарды. Пуставетов һәм Ростовцев иптәшләр „Моряклар“ һәм „Комсомолның сугышчан җыры“ н зур темперамент белән җырладылар. Балет артистлары Әхтәмов һәм Ласточкина китәшләр яратылып караддылар. Гацулак һәм Гацулина татар биюен оста һәм табигый итеп биеделәр.

М. Яхин.

УРАМНАРНЫ ТӨЗЕКЛӘНДЕРҮ

Шәһәр коммуналь хуҗалык бүлеге 1940 нчы елда шәһәр урамнарын һәм шәһәргә якын юлларны төзекләндерүгә хәзерләнә башлады. Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы башкарма комитеты бу эшләргә 1 миллион 500 мең сум акча билгеләде. Нариман урамына капитальный ремонт тәмамланачак. Тукай урамына реконструкция ясала. Аның тротуарларына асфальт җәеләчәк. Кабан күле аркылы 3 һәм 4 нче маршрут трамвай линияләрен тоташтыру өсен дамбалар ясалачак һәм Эсперанто урамы төзекләндереләчәк.

Бауман районындагы урамнарны төзекләндерү өчен 139 мең сум тотылачак.

БЕЛДЕРҮ

ВКП(б) Татарстан Өлкә Комитетының оештыру-инструкторлык бүлеге түбәндә фамилияләре күрсәтелгәннәрнең килүләрен яисә үзләренең адресларын белдерүләрен сорый:

1. Мөсагыйт Биктимер улы Шахмаев—элек Бауман райсоветында эшләгән. 2. Георгий Иванович Тараканов — элек Кукмара районында эшләгән. 3. Александр Александрович Михайлов—элек Кукмара районында эшләгән. 4. Сәхипҗамал Ибраһим кызы Ибраһимова—элек Кукмара районында эшләгән. Габдрахман Насыйров — элек Бөгелмә районында эшләгән. 6. Николай Михайлович Крылов—элек Тәмте районында эшләгән. 7. Николай Александрович Докучаев—элек Казан шәһәрендә Горпромторгта эшләгән.

Җаваплы редактор
һ. АБДРАХМАНОВ.
Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Хезмәт ияләре депутатларының Казан Шәһәр Советы Башкарма Комитеты Шәһәр Советы депутаты

СЕРГЕЙ АЛЕКСАНДРОВИЧ НИКОЛАЕВ

ның шушы ел, 8 нче февральдә вакытсыз үлүен тирән кайгы белән белдерә һәм аның семьясенең кайгысын уртаклаша. 260—1

И. В. Сталин исемендәге ФЗУ мәктәбенең дирекциясе, партия, комсомол һәм профсоюз оешмалары, шулай ук мәктәпнең бөтен коллективы мәктәп сотрудникгы, укыту-производство бүлеге мөдире иптәш

СЕРГЕЙ АЛЕКСАНДРОВИЧ НИКОЛАЕВ

ның шушы ел, 8 нче февральдә вакытсыз кинәт үлүен тирән кайгы белән белдерәләр һәм аның семьясенең кайгысын уртаклашалар. Күмү процесы 10 нчы февраль көндез 3 сәгаттә була. Гәүдәсе мәрхүмнең квартирасыннан алып чыгыла. Карл Маркс урамы, 32-12, кв. 35. 257—1

КАЗАН МУЗЫКА УЧИЛИЩЕСЕ

УЧИЛИЩЕГӘ ХӘЗЕРЛЕК ГРУППАСЫНА;

Музыка училищесенең бүлекләреннән: вокальный, хор, халык музыка кораллары бүлекләре буенча, шулай ук тынлы музыка кораллары бүлегенең флейта, кларнет, труба, волторна классы һәм кыллы-сызгычлы музыка кораллары бүлегенең скрипка һәм контрабас классы буенча

УКУЧЫЛАР АЛА

Скрипка классы буенча—урта мәктәпнең V һәм VI нчы классларында укучылар алыналар. Халык музыка кораллары һәм тынлы музыка кораллары бүлекләре буенча—урта мәктәпнең VI һәм VII нче классларында укучылар, ә вокальный һәм хор бүлекләре буенча—җиде еллык мәктәпне тәгәлләгән үсмерләр алыналар.

Гаризалар һәр көн көндез 10 сәгаттән 2 гә кадәр Музыка училищесе канцеляриясендә алына. Жуковский урамы 4. 245—1

КАЗАН АВИАЦИЯ ТЕХНИКУМЫ

институтның кечке бүлегенең 1 нче курсына

УКУЧЫЛАР АЛА

Техникум авиация промышленносте өчен техник-механиклар һәм техник-технологлар хәзерли.

УКУЛАР ПРОИЗВОДСТВОДАН АЕРЫЛМЫЙЧА АЛЫП БАРЫЛА.

Техникумга 16 дан 30 га кадәрге яштәге ирләр һәм хатын-кызлар алыналар. Техникумга керүчеләр тулы булмаган урта мәктәп программасы күләмендә рус теленнән, математикадан, физикадан, химиядән, СССР халыклары тарихыннан, СССР Конституциясеннән һәм географиядән сынаулар үтәләр.

Тулы булмаган урта мәктәпне 1939 нчы елда „отлично“ билгесе белән тәгәлләүчеләр, шулай ук тәгәлләнгән урта белемле кешеләр техникумга сынаусыз алыналар.

Гариза белән бергә, керүченең тулы автобиографиясе, тулы булмаган урта мәктәпне тәгәлләү турында бирелгән аттестат, яисә керүченең тәгәлләнмәгән урта белемле (урта мәктәпнең 8—9 классын, яисә рабфакның икенче, өченче курсларын тәгәлләгән) булуын, яисә тәгәлләнмәгән югары белемле булуын раслый торган документ, 3х4 сантиметр зурлыгында баш киемсез төшкән, һәрберсенә керүченең имзасы куелган һәм дәүләт учреждениесе яисә йорт управлениесе тарафыннан расланган 3 фотокарточка, сәламәтлеге турында медицина белешмәсе һәм гаскәри учетта торучылардан—хәрби хезмәткә мөнәсәбәте турында белешмә бирелергә тиеш. Болардан тыш паспорт күрсәтелә.

Казан, Чернышевский урамы, 6-18. Телефоннар: 18—89, 43—99 һәм 31—42. Гаризалар һәр көн иртән 9 сәгаттән көндез 4 кә һәм кич 6 сәгаттән 8 гә кадәр алына. 232—1

ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ ФИЛАРМОНИЯСЕ

Кызыл Армия йортында 12 нче февральдә (талон 38) | Дәүләт циркында 14 нче февральдә (талон 39)

ДОН КАЗАКЛАРЫНЫҢ ҖЫРЛАРЫ һӘМ БИЮЛӘРЕ АНСАМБЛЕ

Художество бүлеге мөдире, баш дирижер Д. А. Колонийцев.

Репертуарда: Совет композиторларының әсәрләре, казак халык җырлары һәм казак биюләре.

Касса Кызыл Армия йортында һәр көн һәм Дәүләт циркында 12 нче февральдән көндез 3 сәгаттән кич 9 га кадәр ачык.

Концертлар Кызыл Армия йортында кич 9 да, Дәүләт циркында кич 8 дә башлана.

КАЗАН ШӘҺӘР СОВЕТЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫНЫҢ

СӘЛАМӘТЛЕК САКЛАУ БҮЛЕГЕ

11 нче февраль, кич 6 сәгаттә Шәһәр Советының утырышлар залында, дәвалау-профилактик учреждениеләрнең җитәкчеләре белән берлектә,

Шәһәр Советы депутаты врачларның һәм медицина работникларының киңәшмәсен чакыра —

Көн тәртибе: 1. Шәһәрдә сәламәтлек саклау эшләре һәм 1940 нчы елда алда торган бурычлар (докладчы сәламәтлек саклау халык комиссары иптәш Гинзбург). 2. Шәһәрдә сәламәтлек саклау эшендә Шәһәр Советы депутатларының катнашулары һәм аларның роле (докладчы РСФСР Верховный Советы депутаты профессор Агафонов).

Киңәшмәгә сәламәтлек саклау активы чакырыла.

Шәһәр Сәламәтлек Саклау бүлеге. 242—2—2

КИРӘК:

5 нче Тегү фабрикасына БУХГАЛТЕР-КОНТРОЛЕР, ХИСАПЧЫЛАР һәм электр хуҗалыгының мөдире булып эшләү өчен ЭЛЕКТРИК. Ягодный бистәсе, Гладилов урамы, 51/1. 239—1

Мальтоз-патка заводына (Казан, Галиәсгар Камал урамы, 39, телефоннар: 8—11 һәм 18—37) даими эшкә ашыгыч рәвештә БАШ БУХГАЛТЕР, БУХГАЛТЕР-ФИНАНСИСТ, ХИСАПЧЫ, ТЕПЛОТЕХНИК, ДИПЛОМЛЫ КОЧЕГАР һәм язу машинасында эшләүче МАШИНИСТКА. 238—1

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Автомобиль Транспорты идарәсенә, баш инженер хезмәтләрен үтәү өчен, АВТО ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ИНЖЕНЕР. Казан, Островский урамы, 20. 253—2—1

Даими эшкә РАСЧЕТ БҮЛЕГЕ БУХГАЛТЕРЫ һәм БУХГАЛТЕР-ФАКТУРОВЩИК. Хезмәт хакы килешү буенча. Кызыл бистә, „Пролетарий“ такта яру заводы. 36—84. 247—1

Казан Нефтебазасына (Яңа бистә, Зур Ямашев урамы, 2) даими эшкә КАССИРЛАР, БОНДАРЬЛАР, СЛЕСАРЬЛАР, КОЧЕГАРЛАР, ОХРАННИКЛАР, ЮРИСТ-КОНСУЛЬТ, НОРМАЛАУЧЫ, ЭКСПЕДИТОРЛАР, КАМЕРОНЩИКЛАР, ЙӨК ТАШУЧЫЛАР, ДВОРНИК һәм ЯЗУ МАШИНАСЫНДА ЭШЛИ БЕЛҮЧЕ ЭШБАШКАРУЧЫ. Хезмәт хакы килешү буенча. Кирәк кешеләргә тулай торакта урын бирелә. 235—2—1

Татарстан АССР Совнаркомы янындагы Юллар идарәсенә, районнарда эшләү өчен, юлларда күперләр һәм трубалар салу эшләре белән таныш БЕЛГЕЧ-ДЕСЯТНИКЛАР. Казан Париж Коммунасы урамы, 2. 234—2—1

Таткинотрестка МАШИНИСТКА һәм КИНО-ТЕАТРЛАРДА ЭШЛӘҮ ӨЧЕН ПИАНИСТЛАР. Трестның кадрлар бүлегенә килергә. Бауман урамы, 60. 254—2—1

Галиәсгар Камал исемендәге

Татар Дәүләт Академия театры

12 нче февральдә көндез 12 сәгаттә һәм кич

ТУКАЙ

Талоннар: 113 һәм 114.

Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

БҮГЕН һӘМ һӘР КӨН

Тулысынча яңа программа

ПОПУЛЯР КОМИК, һӘР ТӨРЛЕ ХАЙВАННАРНЫ ӨЙРӘТҮЧЕ, РСФСР ның атказанган артисты, орденлы

М. ЗОЛЛО үзенең антропозоологик труппасы белән.

Касса һәр көн көндез 11 сәгаттән 1 гә һәм кич 5 тән 8 гә кадәр ачык.

Татар Дәүләт Опера театры

Татар Дәүләт Академия театры бинасында

Телефоннар: 30—78 һәм 29—04

Бүген, 10 нчы февральдә

ВОКАЛЬ-ХОРЕОГРАФИК КОНЦЕРТ

Талон 77.

Кич 9 сәгаттә башлана.

Иртәгә Мединститут коллективы өчен, ябык спектакль. Талоннар белән кертелми.

16 нчы февраль, кич 6 сәгаттә Казан Дәүләт университетының зоология аудиториясендә университет гыйльми советының ачык утырышы чакырыла һәм биологик фәннәр кандидаты дигән гыйльми дәрәҗә алу өчен иптәш П. Б. Раскатов тарафыннан, „Экологик тип төрле үсемлекләрдә коллоидларның күләмен билгеләү тәҗрибәсе“ дигән темада халык алдында

ДИССЕРТАЦИЯ ЯКЛАУ

үткәрелә

Рәсми оппонентлар: профессор А. М. Алексеев һәм доцент М. В. Марков.

Утырышка Казан шәһәре югары мәктәпләренең фәнни работниклары чакырылалар. 244—1

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

Бүген, 10 нчы февральдә

МАСКАРАД

Талон 97.

11 нче февральдә

РЕВИЗОР

Спектакльләр кич 7 сәгат 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгат 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгаттән 7 сәгат 30 минутка кадәр кассада сатыла.

ЗУР ТЕАТР ФИЛИАЛЫ

(Киров районы Культура сарае)

11 нче февральдә, шулай ук 12 нче февральдә көндез һәм кич

БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА

Талоннар: 11 ндә 46 һәм 47, 12 ндә көндез 49, 50 һәм кич 51, 52.

Спектакльләр көндез 12 сәгаттә, кич 8 дә башлана.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ФУТЛЯРДАГЫ КЕШЕ
„УНИОН“ 11, 1-20, 3-40, 6, 8-20, 10-30 да.	МИНИН һӘМ ПОЖАРСКИЙ
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да	УНБЕР БАШКАЛА
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	11 нче ИЮЛЬ
„ЧАТКЫ“ 6, 8 һәм 10 да.	КАЙНАР КӨННӘР
„ПИОНЕР“ 10, 11-30, 1, 2, 3-30, 6, 8 һәм 10 да.	Көндезге һәм кичке сеансларда ПАТРИОТ. Көндез 1 сәгаттә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„РОТ-ФРОНТ“ 4, 6, 8, 10 да.	БӨЕК ГРАЖДАНИН (2 нче сериясе)
КУЛЬТУРА САРАЕ 5, 7, 9 да.	һАВА ПОЧТАСЫ